

## Сакаллы кеше язмалары

Ни өчендер, сакал турында сүз чыкса, кешенең тел очында шундук «акыл» сүзе өерелә башлый. Моңа бәлки, халык әйтемнәре дә сәбәпчедер инде (сакалы мең карыш, акылы бер карыш, мәсәлән). Ә бәлки, бу сәбәп түгелдер. Нәтиҗәдер. Ни генә әйтсәң дә, бала-чагага сакал чыкмый ич. Ул җитлеккән, беркадәр тормыш тәҗрибәсе туплаган, димәк, акыл җыйган кешегә чыга. Белмим, әмма сакал сүзен һәрвакыт акыл белән тәңгәлләштерергә тырышу бар. Югыйсә акыл белән сакалның бер уртаклыгы да юк ич инде.

7 БИТ



## Дин исеме белән кан кою дөресме?

Соңгы вакытта шартлатулар, терактлар саны артып китте. Кызганыч, күбесен ислам дине, мөселман халыклары белән бәйләп күрсәтәләр. Үзен мөселман дип йөрүче кеше террорист була аламы? Әгәр Аллаһыга инанган адәмнең кешелеккә каршы кулы күтәрелсә, бу вәхшилекнең чыганагы кайда?

8 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

**Җомга** | 5.08.2016 | № 84 (5702)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# «СЕЗ ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ЯХШЫ КОМАНДАСЫ»




Автор фотосы

**Беренче сыйныфка барыр алдыннан сумкасын йөз кат тутырып, йөз кат бушатып, өйдә сәбәпсезгә дә күтәреп йөргән чакларын күпләр хәтерлидер. Беренче тапкыр, беренче сыйныфка барырга әзерләнү, күрәсең, шунсыз гына булмыйдыр да. Беренче сумка, беренче китаплар...**

Елдан-ел колачлырак була барган «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясе дә меңләгән баланы өр-яңа букчалар белән сөендерә. Бу хәрәкәткә кушылучы аерым кешеләрнең, тулы бер коллективларның саны артуны яхшыга юрарга кирәк. Ул үзе үк республиканың рухын, яхшы эшләргә юнәлтелгән ниятләрен күрсәтеп тора. Быел да акция дәвамында барлык муниципаль берәмлекләрдә аз керемле, ишле гаиләләрдән беренче сыйныфка укырга керүчеләргә, шулай ук инвалид балаларга 9484 портфель тапшыру күздә тотыла.

3 август көнне Казанның Фатиха Аитова исемендәге татарча белем бирүче 12 нче гимназиясендә старт алган әлеге хәйрия акциясе зур бер программаны эченә алган бәйрәмгә әверелде. Беренче сыйныфка баручы балалар ул көнне өр-яңа букчаларны Киров һәм Мәскәү районнары хакимияте башлыгы Сергей Миронов, Татарстан Президентының социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе, хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча республика советы секретаре Ләйлә Фазлыева һәм Казан шәһәре Думасы депутаты Сергей Черепанов кулыннан алдылар.

– Быел Казанда 13,5 мең укучы беренче сыйныфка керә, шуның кадәр бала беренче тапкыр парта артына утырачак. Аларның 3,5 меңе - Киров һәм Мәскәү районнарыннан, – дип, Сергей Миронов кечкенәләргә мәктәптә якын дуслар табарга, өйдәге таянычны тоеп яшәргә һәм 4-5кә генә укырга чакырды. Ләйлә Фазлыева шулай ук балаларны якынлашып килүче уку елы белән тәбрикләде.

– Ышаныгыз: сез Татарстанның иң яхшы командасы. Сезне алда бик зур ачышлар көтә һәм без сезгә зур өметләр баглыйбыз, – дип, балаларның акыллы, сәламәт һәм көчле булып үсүләрен теләде.

Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, хәйрия эшчәнлеге нинди генә булмасын, аларның барысы да мөһим. Ул ярдәм алучыга да, ярдәм күрсәтүчегә дә бер үк дәрәҗәдә кирәкле гамәл. Шул рәвешле безнең күңелебез чистара, җәмгыятьтә үзара кайгырту, ярдәмләшү, игътибар мохите барлыкка килә.

«Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясе шулай ук 2 – 11нче сыйныфларда укучы ярдәмгә мохтаҗ булган 14 меңләп балага мәктәпкә әзерләнүдә ярдәм кулы сузачак.

**Расиха ФӘИЗОВА.**

КАЗАН - ФРАНКФУРТ-НА-МАЙНЕ ДАИМИ РЕЙСЫ

КАЗАННАН ЕВРОПАГА СӘЯХӘТ ИТ!



# Кайсы район өлгеррәк: Буамы, әллә Азнакаймы?

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чүпрәле, Тәтеш һәм Буа районнарында урып-җыю эшләренең барышы белән танышты. Аны премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов озата йөрде.**

УҢЫШ-2016



tatarstan.ru

Чүпрәле районы башлыгы Александр Шадриков әйтүенчә, бүгенгә барлык мәйданнарның 41 процентында уңыш җыелган, бу – 16 мең гектардан артык дигән сүз. 45 мең тонна икмәк җыеп алынган, бер гектардан уртача 28,5 центнер уңыш чыга.

Ә Буа районы урып-җыю эшләренең экваторын узган инде. Кайбер хуҗалыклар хәтта барлык ашлыкның 60 процентын сукты-рып алган. Район башлыгы Азат Айзатуллов төрле хуҗалыкларда уңыш күрсәткеченең төрлечә булуын әйтте. Уҗым культуралары яхшы уңыш биргән.

– Арпа, борчак, сабан бодаена тотындык. Тулаем алганда, алдынгы «Авангард» хуҗалыгы уңыш җыюны гектарыннан 45-50 центнер күләмендә төгәлләр дип уйлыйбыз, – диде ул.

Райондагы башка эшләр дә вакытында эшләнә. Салам җыела, җир әзерләнә. Орлык җитештерүче күп кенә хуҗалыклар югары сортлы орлыклар, аларны яңартып тору, яңа технологияләр нәтиҗәсендә зур уңыш алуга ирешә. Президент та, район башлыгы да мондый уңышка ирешүнең 50-60 проценты технологияләргә бәйле, дип саный.

Буада соядан кала барлык урып-җыю эшләре якынча ике атнадан тәмамланыр дип өметләнәләр. Марат Әхмәтов күптән түгел генә монда урып-җыюның барышы уңаеннан очрашулар булганын, эшкә анализ ясалганын әйтте.

– Биредә басулар бик яхшы. Буа районы культуралардан югары уңыш алып, гел алдынгылар рәтендә йөри. Быел биредә җыелган ашлык күләме буенча иң югары уңышка ирешергә омтылалар. Азнакай, Нурлат, Зәй районнары да аннан азга гына калышыр, мөгаен, – диде министр.

Рөстәм Миңнеханов, бу сүзгә җавап итеп:

– Азнакай, беренче урынны алам дип чыгып китте, – диде.

– Азнакайның Баулыга якын ягы корылыктан күбрәк зыян күрде, аңа карамастан, аларда да уңыш яхшы булырга тиеш. Ә Буа ел да шушы югары күрсәткечләрне бирә, – диде Марат Әхмәтов.

Тәтеш кырларын карап йөргәндә, ул коры һава торышының быелгы уңышка зыян салуын әйтте. Шулай да, Тәтеш иң күп уңыш җыеп алучы районнарның берсе.

– Тәтешлеләр моңа узган елның көзеннән үк әзерләнә башлаган инде. Кырда эшләнергә тиеш барлык эшләрне дә вакытында башкарып чыктылар. Бүген районның корылыкка чыдамлылыгы бик көчле, – дип саный Марат Әхмәтов.

**Татарстан районнарында «Бердәм Россия» партиясенең мобиль кабул итү пунктлары эшли башлады. Проект партиянең сайлау алдыннан уза торган агитация программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Махсус график буенча, партия активистлары, һәр көнне автобусларга утырып, республика шәһәрләре һәм районнарына чыга. Агитаторлар конкурс аша сайлап алынган. Сайлап алганда өстенлек профессиональ юристларга бирелгән. Агитаторларның бөтен командасы тренинглар узган.**

## «Бердәм Россия» партиясенең мобиль бүлмәләре эшли

Татарстанда яшәүче һәр кеше үзе яши торган җирлеккә килгән мобиль кабул итү пунктына мөрәҗәгать итә, үзен кызыксындырган соравын бирә, теләк-тәкъдимнәрен җиткерә ала. Халыктан кабул итеп алынган мөрәҗәгатьләр депутатлыкка кандидатлар өчен бик мөһим, чөнки шулар нигезендә, алар Дәүләт Думасында депутатлык эшчәнлеген төзи.

Киров һәм Мәскәү районнарында эшләүче мобиль кабул итү пункты өч пунктта булырга өлгергән. Әлеге пунктта эшләүче Александр Артемьев сүзләренчә, алар һәр туктаган урыннарында икешәр сәгать эшли.

– Йортларга мобиль кабул итү пунктлары килүе турында игъланнар эленгән. Дүрт кеше эшлибез, агитация материаллары таратабыз. Халык килә, сорауларын бирә. Алдагы еллар тәҗрибәләреннән чыгып әйткәндә, халык белән очрашулар кирәк, аларның проблемаларын, гозерләрен ишетәбез. Сайлау алды кампаниясенең максаты да бит – һәр кешегә барып җитү, – диде ул безгә.

СҮЗ УҢАЕННАН

# Икмәк барда, тормыш бар

**Татарстанда һәр дүртенче кешенең тормышы авылга бәйле. Инде күп еллар безнең республика игенчелек һәм терлекчелек буенча Россиядә алдынгы төбәк булып санала. Узган ел йомгакларыннан күренгәнчә, авыл хуҗалыгы өлкәсендә җитештерелгән тулаем продукция күләме 214 миллиард сумлык булган. Бу күрсәткечләр буенча Татарстан Россиядә дүртенче урында тора.**

Соңгы елларда авыл хуҗалыгы тармагы шактый алга китте. Чәчүлек мәйданнарының һәр гектарыннан 25-30 центнер уңыш җыю гадәти күренешкә әйләнде. Уңдырышлылык 40ар центнерга җиткән һәм аннан артып киткән еллар да булды. Сөтчелек фермаларында соңгы елларда һәр сыердан 5000 килограммнан артыграк сөт савыла. Мөгезле эре терлекләрнең баш саны да елдан-ел арта бара. Бу юнәлештә Татарстан Белгород өлкәсеннән генә калыша.

Бүген авыл хуҗалыгы тармагы алга киткән икән – бу дәүләт сәясәтен уңышлы алып бару, авылга инвестицияләр кертү, яңа технологияләр куллану, социаль өлкәгә игътибарны арттыру нәтиҗәсе. Бездә авыл хуҗалыгы тармагына аерым игътибар бирелә: авыл тормышын яхшыртуга, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән дәүләт программалары эшли, шулай ук фермаларны төзекләндерү, силос-сенаж траншеялары төзү программалары да уңышлы эшләп килә.

2010 елдан башлап республикада гаилә фермалары төзелеп килә. Бүген аларның саны 1280нән артып китте. 420 меңләп шәхси хуҗалык дәүләт ярдәме белән төрле юнәлештә үз эшчәнлекләрен башлап җибәрделәр.

– Бүген фермерлык белән шөгыльләнүче эшмәкәрләр зур ихтирамга лаек. Соңгы елларда хуҗалыкларда барлыкка килгән үзгәрешләр авылның киләчәген күзаллауны кыенлаштырды, нәкъ менә шул вакытта алар үзләренә зур җаваплылык алып, булган хәзинәдән дөрес юнәлештә файдалана башладылар. Бүген республика җитәкчелегенең максаты – шундый эшкуарларны саклап калу һәм алар үрнәгендә тагын берничә буын эшкуарлары тәрбияләү, – ди Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов. Югары технологияле комплекслар кулланып, 2018 елга ит җитештерүне 500 мең тоннага кадәр җиткерү күздә тотыла. 2013 елдан эшли башлаган «Казан» агросәнәгать паркы җирле фермерларга үзләре җитештергән продукцияне урнаштыру мөмкинлеген бирде. Бүгенге көндә районнар үзләрендә дә шундый кече агросәнәгать парклары төзи башладылар.

**Айрат ХӘЙРУЛЛИН,** Россия Дәүләт Думасы депутаты, Дәүләт Думасының аграр мәсьәләләр комитеты рәисенең беренче урынбасары, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы:

– Бу ел игенчеләр өчен уңышлы килде. Узган ел бодайның бер тоннасы 12 мең сумга сатылды, быел да шул бәя саклансын өчен, безнең бөтен алшартлар да бар. Икмәк бәясе узган елгы дәрәҗәдә сакланырга тиеш, аның күтәрелүенә бернинди объектив сәбәп тә юк. Минем фикеремчә, быел без бәяләрне узган елгы дәрәҗәдә саклап, авыл хезмәтчәннәрен дә бәхетле итә, шул ук вакытта шәһәр кешеләрен дә сыйфатлы икмәк белән шатландыра алачакбыз. Яхшы уңыш – һәркем өчен зур сөенеч, тегермәнчеләр һәм икмәк пешерүчеләр, икмәк кыйммәтләнмәсен өчен, бәяләрне «авызлыклап» тора ала, монда мин бернинди каршылык та күрмим. Чит илдә ашлык арзаная һәм бәяләрнең очсызлануы бар дигән сүзләр йөри. Әмма биржа бәясенә карап кына эш итәргә ярамый. Биржа бәясе ул товар ашлыгы түгел. Бүген Мексика култыгында Америка бодае 186-187 АКШ доллары тора, Россия ашлыгы да шул ук бәягә сатыла, өстәвенә 10 процент НДС кире кайта. Хәзерге вакытта дөнья базарында Россия ашлыгының тоннасы уртача 15-16 мең сумга сатыла – бу бик яхшы бәя. Безнең фикеребезчә, әгәр игенчеләребез азык-төлек бодаеның бер тоннасы өчен 12 мең сум алса, бу – бик тә гадел булачак. Ә калганын әнә трейдерлар эшләсен.

# «Бу балалар бакчасы һава кебек кирәк иде»

**Бер көн эчендә Буаның Үзәк паркында, районның Бикмураз авылында – «Миләшкәй» балалар бакчасы, Чүпрәле районында Балалар иҗат йорты һәм балаларны савыктыру лагеры ачылды.**



**Зөһрә САДЫЙКОВА**

Татарстанда авыллар үсешенә йөз тотучы берничә социаль программа тормышка ашырылып килә. Алар кысаларында мәдәни үзәкләр, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, универсаль спорт мәйданчыклары төзелә. 2011-2015 елларда гына авылларда 200гә якын балалар бакчасы ачылган. Буа һәм Чүпрәле районнарындагы «өй туйлары» да – шул программалар нәтиҗәләре.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Буаның Үзәк паркында Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырлар истәлегенә куелган мемориалга һәм Социалистик хезмәт геройлары мемориалына чәчәкләр салды. Президент ярдәмчесе Наталья Фишман җиткергән мәгълүматлар буенча, паркта төзекләндерү соңгы тапкыр 25 ел элек башкарылган булган. Быел төзекләндерү эшләре ике этапка бүлеп үткәрелә. Икенче этапка кертелгән эшләрне Төзүчеләр көненә төгәлләү ниятләнелгән. Әлеге вакытка паркка керү капкасы ахырына кадәр эшләп бетерелмәгән, беседкаларны, сәхнәне тәмамлыйсы, яктырткычлар, эскәмияләр куясы бар.

80 урынга исәпләнгән «Миләшкәй» балалар бакчасын ачу тантанасында Рөстәм Миңнеханов быел Татарстанда 56 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе төзекләндерелүен әйтте, бу программаның алдагы елларда да дәвам иттереләчәген билгеләде. Шунысы мөһим, илдәге икътисади вазгыять катлаулы булуга карамастан, республикада утыздан артык социаль программаның берсе дә туктатылмады.

– Мәктәпкәчә белем бирү баскычы - яшь буын тәрбиясендә мөһим этап. Балалар бакчасы ул вакыт уздыру урыны гына түгел, ә чып-чын мәктәп. Биредәге атмосфера көндәшлеккә сәләтле киләчәк буыныбызны тәрбияләрлек булырга тиеш, – диде республика җитәкчесе.

Бакча мөдире Лилия Вәлиуллина балалар бакчасына сөенүне яшермәде.

– Ул безгә бик кирәк иде, - диде ул. – Авыл үсә, яңа йортлар төзелә. Әле тагын 140 йорт төзелә. Яшь гаиләләр, балалар күп. Бу балалар бакчасы һава кебек кирәк иде.

Ул быел республикада балалар лагерьларын яңарту буенча зур эшләр башкарылганлыгына да тукталды.

– Бу лагерьларда көньяк савыктыру урыннарындагы кебек үк шартлар тудырырга кирәк. Балалар үзебездә дә әйбәт ял итә алалар икән, курорт төбәкләренә бару өчен вакыт һәм акча туздырырга кирәкми, – диде ул.

«Чайка» лагеры 60 нчы еллардан ук эшли. 2015 елның сентябрендә капиталь ремонт өчен акча бүленеп бирелгән, әмма ремонтлап кына калмыйча, төп объектларны кире төзегәннәр. Әйтик, яңа йокы корпусы, ашханә, спорт мәйданчыклары һәм башка корылмалар төзелгән. Нәтиҗәдә, урыннар саны да 70кә арткан. Бүген инде биредә өченче смена балалар ял итә. Киләчәктә «Чайка» лагеры ел дәвамында эшләр дип ниятлиләр.

# «Халык контроле» күзәтү астында

**Дәүләт хезмәтләре порталында «Халык контроле» дип аталучы проект эшләп килә. Махсус мәгълүмати система ярдәмендә биредә теләге булган һәркем үзенең соравын калдыра ала.**

**Зөһрә САДЫЙКОВА**

Республиканың премьер-министр урынбасары – мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов китергән мәгълүматларга караганда, системада бастырылган мөрәҗәгатьләр саны быелтыр шушы ук вакыт белән чагыштырганда, 49 процентка арткан. Шулардан хәл ителгәннәре ике процентка күбрәк. «Халык контроле»нә кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең иң популяр категорияләре – «Территорияләрне уңайлату» (барлык мөрәҗәгатьләрнең 35 проценты), «Муниципаль юлларны карап тоту һәм төзекләндерү» (23 процент), «Юл хәрәкәтен оештыру», «Торак-коммуналь хезмәтләр» һәм «Җәмәгать транспорты». Дөрес, категорияләр арасында бик үк популяр булмаганнары да бар. Мәсәлән, «Хезмәттә куркынычсызлык таләпләрен бозу» категориясе 2015 елның маеннан бирле гамәлдә булса да, анда бер генә мөрәҗәгать тә юк. Шулай ук «Үтеп йөрү яки транспортта узарга комачаулаган юлдан читтәге автомобильләр» категориясе исә «халык контроле» мобиль кушымтасын кабатлый. Киләчәктә әлеге категорияләр алып ташланырга мөмкин.

Татарстанның әлеге дәүләти мәгълүмат системасының эшенә багышланган киңәшмәдә Татарстан хөкүмәте башлыгы Илдар Халиков та катнашты.

– Программа халыкта зур ышаныч яулады һәм без ихтыяҗ барлыгын күреп торабыз, – диде ул, системаның инде дүрт елга якын вакыт эшләвен искәртеп. – Программа шактый уңайлы булып чыкты. Ул актив файдаланышта, күчермәсе алынып, тормышның башка өлкәләренә кертелә.

Татарстанлылардан көн саен 180 мөрәҗәгать кабул ителә, аларны хәл итү буенча 80 карар чыгарыла. Шул исәптән 50дән артыгы – Казанда. Илдар Халиков сүзләре буенча, кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең 80 процентын хәл итәр өчен өстәмә финанслау таләп ителми. – Кайвакыт теге яки бу мәсьәләне хәл итәр өчен – бер мең, күп дигәндә, ун мең сум акча да җитә, тик ни өчендер бу мөрәҗәгатьләр игътибардан читтә кала. Сүз кайдадыр күпер салырга кирәк, дигән мөрәҗәгать турында бармый, монда аңлашыла, бездә андый акчалар каралмаган. Кайвакыт күпер салу турында түгел, эскәмия кую да хәл ителми. Шуның өчен аларга игътибарлырак булырга, 2017 ел өчен программа төзегәндә, анализ ясап, «Халык контроле»нә мөрәҗәгатьләрне район башлыклары белән уйлашырга кирәк, – диде ул.

Ә менә Татарстанның кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская әйтүенчә, эшне башкаручыларның формаль җаваплары, эшне сузулары, мәсьәләне хәл итүне һаман чигереп килүләре аркасында атна саен утыз мөрәҗәгать кире кайтарыла икән. Моннан тыш, контроль вакытны билгеләү буенча да проблемалар барлыгын әйтте. – Кайвакыт эшне башкаручылар сезонга бәйле булмаган вакытлар куя. Мәсәлән, Казанның Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе 2015 елның апрелендә йорт ишегалдындагы юлны төзәтүне ноябрьдә эшләргә планлаштырган иде. Шулай ук люк капкачларын ябу буенча да сораулар күп. Ипподром һәм Дементьев урамнарындагы люкларны ябу буенча гариза узган елның июль башында алынган иде. Ә проблеманы хәл итү быелның август аена калдырылган. Әлеге мәсьәләләр без шәһәрнең тышкы төзекләндерү комитетының исенә төшергәч кенә хәл ителде, – диде ул.

**1 августтан эшләүче пенсионерлар өчен пенсия арттырылды. Дөрес, өстәмә түләнә торган сумма бик аз, ләкин акмаса да, тама дигәндәй, ярап куя. Пенсиянең арту күләме кешенең хезмәт хакына бәйле, берәүләр бу үсешне сизмәскә дә мөмкин, икенчеләр август аеннан берничә йөз сумга күбрәк ала башлаячак.**

# Акмаса да, тама

Ә менә пенсия өлкәсендәге яңа кагыйдәләр буенча, 2016 елдан эшләүче өлкәннәрнең пенсияләре индексацияләнмәячәк. Эшләвен туктатырга уйлаган пенсионерлар турындагы мәгълүматны аларның оешмасы Пенсия фондына хәбәр итәргә тиеш. «Пенсионерның эшләми икәне билгеле булгач, аның пенсиясе, ул эшләгән вакытта үткәрелгән индексация күләменнән чыгып, арттырылачак», - дип хәбәр итә Татарстан Пенсия фондының Совет районы буенча бүлеге матбугат үзәге җитәкчесе Роза Минапова. Сүз уңаеннан, быел картлык буенча пенсияләр 1 февральдән 4 процентка арткан иде.

**Татарстан Пенсия фондыннан алынган мәгълүматлар буенча, республикада 1,1 миллион пенсионер исәпләнә. Шуларның 400 меңе картлык буенча пенсиягә чыкса да, эшләвен дәвам итә.**

# Метро үсеше турында федераль программа кирәк




**Казанның үсеш стратегиясе буенча фикер алышулар дәвам итә. Мондый документлар ел ахырына кадәр республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә кабул ителергә тиеш. Татарстанның һәр территориясе үсешен системалы билгеләүче комплекслы программалар бу. Универсиадага әзерлек барышында Казанның транспорт системасы җитди үзгәреш кичерде. Башкалада юл челтәрен төзеп, капремонт ясаганнан соң, урамнардагы уртача тизлек ике тапкырга диярлек артты – 15 км/сәг. тән – 40 км/сәг. кадәр җитте.**

Казан стратегиясе буенча узган «түгәрәк өстәл»дә Иршат Минкин метро үсеше турында федераль программа кирәклеге хакында чыгыш ясады. Шунда ук КГАСУ янындагы 15 елда Татарстан башкаласының үсеш моделен тәкъдим итте.

Казанның 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләү кысаларында архитектура-төзелеш университетында транспорт һәм территориаль үсеш буенча «түгәрәк өстәл» узды.

«Түгәрәк өстәл» эшендә Казан мэриясе порталында узган интернет-анкета барышында шәһәр үсешенә кагылышлы кызыклы тәкъдимнәр ясаган казанлылар да катнашты.

Университетның шәһәр төзелеше кафедрасы мөдире профессор Александр Дембич:

– 2030 елга Стратегия өстендә эшләүнең беренче этабы нәтиҗәсе шуны күрсәтте, шәһәрнең пространстволы үсешенең төп сценариенда бер генә үзәкле түгел, ә активлыгы ягыннан бернигә үзәге булган шәһәрне сайлау торды.

Казан ул –хәзердән үк үзенең үзенчәлеге, ресурслары һәм функцияләре белән аерылып торган метрополис, – дип билгеләп үтте һәм алар тиешле транспорт элемтәсе белән тәэмин ителергә тиеш дип аңлатты.

Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат Иршат Минкин транспорт-күчереп утырту төеннәре метро станцияләре нигезендә формалашсын дип тәкъдим итте.

– Бу районнарның һәм тулаем шәһәрнең үсешенә гаҗәеп импульс бирәчәк. Метроларның үсеше шәһәр үсешенең умыртка баганасы булырга тиеш, – дип басым ясады ул. Һәм «түгәрәк өстәл»дәгеләрнең игътибарын илдә метро төзелеше буенча максатчан федераль программа булмавына юнәлдерде. Шуның аркасында Мәскәү белән Санкт-Петербургтан кала миллион халкы булган барлык шәһәрләрдә җир асты юллары төзү, нигездә, туктады. «Казан исә шәһәрдә бер генә түгел, һич югы ике-өч линия булуга бик мохтаҗ, – дип белдерде ул.

Очрашуга эксперт сыйфатында Мәскәүдән чакырылган Елена Боровик: «Транспорт мәсьәләсенә килгәндә, Казан, бәхәссез, Россиядә иң яхшы шәһәр», – дип ассызыклады. Эксперт шулай ук Казанда җәяүлеләр хәрәкәтендә куркыныч урыннарның күп булуын, вакыты белән тротуарларның кинәт өзелү очраклары булуын белдерде. Ул күбрәк шәһәр эче районнарындагы юллар челтәре үсешенә игътибар бирергә һәм дөньяның күп кенә башкалаларындагы кебек, трамвайлар һәм метроның бердәм челтәрен булдыру турында уйларга киңәш итте. «Бүген кеше пространствоны вакыт белән үлчи. Транспорт пространствоны кыса, шуңа күрә транспорт ул – вакыт, кешенең тутырып бетереп булмый торган төп резервы», – дип билгеләп узды Елена Боровик.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча ГИБДД идарәсе җитәкче урынбасары Рөстәм Гәрәев кызыклы мисаллар китерде. Ул 2006 елдан юл-транспорт вакыйгаларында үлүчеләр саны ике тапкыр, ә аварияләр саны 38 процентка кимеде дип билгеләп үтте. Күп дәрәҗәле юл чишелешләре төзүнең нәтиҗәлелегенә Татарстан Экология министрлыгының дәүләт экологик экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүне тәртипкә салу идарәсе җитәкчесе Рәисә Шәһидуллина да тукталды. Ул юл чишелешләре төзелешеннән соң торак йортлар тирәсендә һаваның пычрану дәрәҗәсенең кимүе хакында мәгълүмат китерде. Рәисә Шәһидуллина аерым бер юл кишәрлекләрендә Мәскәүдәге кебек хәрәкәтне чикләү варианты шәһәр өчен котылгысыз дип саный. һәм ведомство тиешле тәкъдим белән, ГИБДДга мөрәҗәгать итәргә җыена.

Казанның баш архитекторы урынбасары Тимур Кадыйров полицентричность принципы Генпланны эшләүчеләр (ГУП «НИиПИ Генплана Москвы».) тарафыннан да исәпкә алынуын белдерде. Казанда 2030 елга кадәр 11 үсеш ноктасы формалаштыру күздә тотыла. Бу вакытка шәһәр халкы 1 млн. 430 мең булачак.

***БЕЛЕШМӘ***

*Исегезгә төшерәбез, Казанның 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләү 2016 елның февралендә башланды. Июньгә документлар әзерләүнең беренче этабы төгәлләнде. Экспертлар Татарстан башкаласының киләчәген ничек күзаллауларын 50дән артык тематик мәйданда бәян иттеләр. Интернет-анкета һәм социаль сораштыру барышында казанлылар киләчәктә башкала нинди юлдан барырга тиешлеге хакындагы фикерләрен җиткерделәр. Стратегиянең беренче этабын эшләүгә 2,5 меңнән артык кеше җәлеп ителде.*

**Эшмәкәрләр хостеллар турындагы закон кабул иткәндә, аларның мәнфәгатен күз алдында тотуны сорый.**

## Игътибар үзәгендә – хостеллар

Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрлек буенча советның киңәйтелгән утырышы узды. Чарада катнашкан Рөстәм Миңнеханов эшмәкәрләр белән республикада кече бизнесны үстерү мәсьәләләре турында сөйләште. Бизнес белән хакимият арасында турыдан-туры элемтәне тәэмин иткән әлеге советның проектлар төркеме эшенә теләгән һәр эшмәкәр кушыла ала. Проект төркемнәре конкрет проблема яки мәсьәләне күз алдында тотып оеша. Бу юлы совет утырышының игътибар үзәгендә хостеллар эшчәнлеге булды.

Татарстан Россиядә кунакханә хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә алга киткән төбәк санала, кунакханә базарындагы вазгыятьне билгеләүче күрсәткечләр буенча Идел буе федераль округында беренче булып тора. Республика килгән кунакларның саны буенча да беренче бишлеккә керә. Бүгенге көндә урта класска исәпләнгән туристлык инфраструктурасын һәрьяклап үстерү перспективалы юнәлеш булып тора. Россиянең эре шәһәрләре арасында иң беренче булып хостеллар Казанда барлыкка килде. Бу өлкәдә Казанның тәҗрибәсе зур. Шул уңайдан Татарстан хостеллар турында федераль закон проектына җитди төзәтмәләр әзерләде. Документ июнь башында беренче укылышта кабул ителде. Ул хостелларны торак йортларда ачуны тыя. Бу исә бизнес вәкилләре арасында җитди резонанс тудырды. Казан эшмәкәрләре Дәүләт Думасы депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы Александр Сидякиннан кунакханәләрне торак йортта урнаштыру турындагы законны караганда аларның мәнфәгатьләрен истә тотуны сорады. Уртак көч белән, торак йортларда яшәүчеләрнең дә, эшмәкәрләрнең дә мәнфәгатен яклаучы вариантлар табылды. Төзәтмәләр хостелларны торак йортта ачу өчен ике төрле шартны үтәүне күз алдында тота. Алар: торак йортта яшәүчеләрнең ризалыгы һәм кунакханәләрнең суга, утка аерым счетчигы булу. Шул рәвешле ике якның да мәнфәгате исәпкә алына. Закон проектын Дәүләт Думасының яңа составы караячак.

# Билен кысып буган, диләр

**Быел язгы-җәйге чакырылыш вакытында 20 мең Татарстан егете солдат каешы такты. Татарстан егетләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча Россия төбәкләре арасында беренче урында тора.**

**Алисә САБИРОВА**



rtr-vesti.ru

Гадәттә, егетләр югары уку йортына кереп, армиягә китүдән вакытлыча котылып кала. Ләкин хәрби бурыч өстән төшми. Быел югары уку йортын тәмамлаган 5721 егетнең 1097се «кармакка эләкте». Урта һөнәри белем алучылар армиягә теләбрәк бара, 5320 кешедән 2019ы хезмәткә чакырылган.

Инде берничә ел рәттән «дипломлы» егетләргә мәҗбүри армия хезмәтен контракт буенча хезмәткә алыштыру мөмкинлеге бар. Бу очракта алар ике-өч еллык килешү төзи. Быел 36 егет әлеге программадан файдаланган.

– Бу чакырылышта беренче тапкыр хәрби комиссариатта һәр солдат өчен электрон карта булдырылачак. Анда хезмәт итүче турында мәгълүмат һәм медицина белешмәсе булачак. Шулай ук аның аша солдатның хезмәттә, учетта яки резервта торуын белеп булачак, – диде Татарстан Хәрби комиссариатының гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру бүлеге башлыгы Дмитрий Гурылев.

Кулына корал тотып хезмәт итәсе килмәгән егетләр альтернатив хезмәтне сайлый ала. Гадәттә алар почта бүлекчәләрендә эшли. Язгы чакырылышка әлеге хезмәткә 11 егет сайлап алынган. Инде көзге чакырылышка да 18 гариза тапшырганнар, аларның 15е генә хупланган.

Армия тормышында иң дәрәҗәле булып саналган Президент полкында быел ун Татарстан егете хезмәт итәчәк. Соңгы дүрт ел эчендә генә дә полкта республикадан 210 кеше хезмәт иткән. Ләкин бу полкка эләгү җиңелләрдән түгел, анда хезмәт итү өчен яшьләр җиде кат иләк аша үтә. Бу гаҗәп тә түгел, ил армиясенең йөзе бит.

Тикшеренү вакытында өч Казан егетенең анализларында наркотик тапканнар. Андыйларга армиягә юл ябык. Хәзерге вакытта егетләр учетка бастырылган.

Безнең егетләрне күбрәк шефлык элемтәләре урнаштырылган частьларга җибәрергә тырышалар. Татарстан районнары 57 хәрби часть белән элемтәләрен җайга салган. Быел аларга ике меңгә якын егетне җибәргәннәр. Район җитәкчеләре дә үз районыннан ил чиген саклаучыларның хәлен белеп кайта икән.

– Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил яшьләрне хезмәт итү урыннарына озатып, аларның хәлләрен белешә башлагач, солдатлар арасында зарланулар бермә-бер кимеде, – диде Дмитрий Гурылев.

Башкалар белән чагыштырганда, армиягә яраклы егетләр саны буенча да без алдынгы. Гадәттә, сөяк-мускуллары системасы, кан әйләнеше авырулары, психик тайпылышлары булганнар хәрби хезмәткә алынмый.

# Татарстан районнары «Сәламәтлек чакрымнары»н үтә




arsk.tatarstan.ru

**«Татарстан командасы» иҗтимагый инициативасы башлап җибәргән «Сәламәтлек чакрымнары» проектын бөтен республика эләктереп алды. Бу атнада гына да Татарстан районнары йөзеп, йөгереп, велосипедта йөреп, төрле дистанцияне узды.**

**Алисә САДРИЕВА**

«Сәламәтлек чакрымнары»ның беренче адымнары 16 июль көнне Казан – Иннополис арасын узу белән башланып киткән иде. Бер төркем велосипедчы бу дистанцияне Татарстанның спорт җиңүләренә багышлады. Хәрәкәтне Арча, Кама Тамагы, Питрәч, Актаныш, Менделеевский муниципаль үзәкләре дә күтәреп алды, районнарның спорт яратучы бер төркем активисты шулай ук велосипедта үз «Сәламәтлек чакрымнары»н узды.

Арча районы өчен велохәрәкәтләр оештыру инде гадәти хәл. Алар җәй дәвамында – олысы да, кечесе дә, түрәсе дә, гади эшчесе дә «тимер ат»ларыннан төшмиләр икән. Быел да 1 август көнне шәһәр буйлап 97 кеше ике чакрым юк үткән.

– Без бу спорт бәйрәмен мәдәни чаралар белән дә баетып, район халкына үзенә күрә бер бәйрәм ясадык. Районның «Созвездие – Йолдызлык» фестивале катнашучылары, үзешчәннәр спортчыларны җыр-биюләре белән дәртләндереп торды. Район үзәгендә майдан алып октябрь аена кадәр шулай велохәрәкәтләр үткәреп торабыз. Даими рәвештә велопрокатлар эшләп тора. Менә әле Белем бәйрәменә дә зур спорт чарасы оештырабыз, – диде Арча районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе Зиннур Сәгыйтов.

Менделеевск районы исә иң зур делегациясе белән шаккатырды. Бүген «Сәламәтлек чакрымнары»н биредә ике йөз кеше үтәчәк.

– Бездә һәр шимбәдә шәһәркүләм иртәнге зарядкалар уза. Анда 60-70 кеше даими йөри. Баскетбол, волейбол уеннары оештырыла. Спорт белән яшьләр генә түгел урта һәм өлкә буын да актив шөгыльләнә. Шуңа да «Сәламәтлек чакрымнары»н үтәргә бик күп кеше теләк белдерде. Мондый чаралар аша без спортка, сәламәт яшәү рәвешенә генә өндәмибез, ә Татарстанны, Менделеевскины яратырга өйрәтәбез, – диде «Татмедиа» АҖ филиалы – «Менделеевск» мәгълүмат үзәге директоры Джулия Искәндәрова.

Чарада «Мин яратам сине, Менделеевск» дигән билге дә куелачак. Велохәрәкәт «Кристал» бию төркеме үткәргән флешмоб белән тәмамлана.

Республика яшәешенә битараф булмаган кешеләр тупланган «Татарстан командасы» атна саен диярлек төрле кызыклы чаралар оештыра. Инде фотосурәтләр конкурсы, балалар тәбрикләмәсе, шигъри эстафета, «Бишлелек иртә» дигән чаралар бөтен республика буенча таралды.



yalkyn.com

# Монда тарих та, мәдәният тә, археология дә бар

**КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге 1 сентябрьдән Габдулла Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе исемен йөртәчәк. Татарда, исеменә күрә – җисеме, дигән яхшы әйтем бар. Исем алмаштыру институтның эчтәлегенә ничек йогынты ясаячак? Нинди яңалыклар көтелә? Бүлек мөдире профессор Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова белән без шул хакта сөйләштек.**

Быел КФУда 196 кешегә «Татар теле һәм әдәбияты белгече» дигән диплом тапшырылган. Диплом алучыларның 24е магистратураны тәмамлый. Үзгәрешләр, иң беренче чиратта, институт әзерләп чыгара торган магистрлык программаларына кагыла.

– Магистратура программалары алмашып торырга, креатив, кызыклы, заманга җавап бирә торган булырга тиеш, – диде Әлфия Юсупова, үзгәрешләрнең нигезендә ни ята дип сорагач. Быел гамәлдә булган «Мәдәниятара багланышларда төрки телләр», «Әдәби тәнкыйть һәм мөхәррирлек», «Татар теле һәм әдәбияты: заманча технологияләр» дигән магистрлык программалары урынына яңалары барлыкка киләчәк. Институтта татар теле белән бәйле дүрт магистрлык программасы булачак. Болар – гамәлдәге «Мәдәниятара багланышларда төрки телләр» һәм өч яңа юнәлеш: «Татаристика», читтән торып укырга кабул итә торган «Тәрҗемә: татар-инглиз, инглиз-татар теле» һәм педагогик юнәлешле «һөнәри аралашуда татар теле» дигән магистрлык программалары. Быел 47 бюджет урын бүлеп бирелгән. Шуларның 12се – татаристика юнәлеше өчен каралган.

Әлфия Юсупова җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырган «татаристика» сүзенә аңлатма биреп, болай диде:

– Татаристика ул – татар теле һәм әдәбият кына түгел. Монда тарих та, мәдәният тә, археология дә бар.

Ягъни биредә төп урынны татар халкының теле, әдәбияты, тарихы алып торачак дигән сүз. Бу өлкәдә белемне бүлек галимнәреннән тыш, исемнәре республикада, Россиядә, дөньяда яхшы таныш филологлар, тарихчылар һәм тюркологлар, археологлар бирәчәк. Мәсәлән, Америкада яшәүче милләттәшебез, татар галиме Юлай Шамил – огълы инде килергә теләк белдергән. Моннан тыш уку планы буенча КФУ Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Халыкара мөнәсәбәтләр, Көнчыгышны өйрәнү һәм тарих институты белән берләләп эшләячәк. Татар халкы тарихы буенча кызыклы дәресләрне, әйтик, татар китабы тарихы, татар диаспорасы тарихына кагылышлы фәннәрне алда аталган институт галимнәре алып барачак. Бу уңайдан план төзегәндә киңәшләшеп эш ителгән. Программа кысаларында дәресләрне бүгенге көндә танылган галимнәребез Искәндәр Гыйләҗев, Фаяз Хуҗин, Җәүдәт Миңнуллин укыячак. Билгеле фольклорчылар, сәнгать әһелләрен чакыру күздә тотыла. Нигездә, дәресләр татар телендә барачак.

«Мәдәниятара багланышларда төрки телләр» программасында белем алучыларга арадашчы булырак төрек телен дә өйрәтү күздә тотыла. Дәресләрне Төркия галимнәре алып барачак. Төрек телен белмичә дә укырга керергә мөмкин. Аны башлап өйрәнү мөмкинчелеге булачак, диде әңгәмәдәшем. Магистрлык программалары игълан ителүгә, белем алырга теләүчеләр өчен бушлай төрек теле курслары да оештырылган булган. Керү имтиханы итеп тел белеме фәне куелган. Әлфия Юсупова сүзләренчә, әлеге программа башка төрки төбәкләрдән, республикалардан килгән студентлар арасында бик популяр икән. Чуашстан, Башкортстаннан, хәтта Төркия белән Кытайдан да килеп белем алучылар бар икән.

– Педагогик юнәлешле «һөнәри аралашуда татар теле» дигән программа, нигездә, югары һәм урта белем бирүче уку йортлары өчен укытучылар әзерләүне күздә тота. Максатчан рәвештә татар телен югары һәм урта уку йортларында укыта алырлык белгечләр әзерләячәкбез, – ди бүлек мөдире. Биредә төп басым татар телен укытуда алдынгы методикаларны үзләштерүгә, аларны татарчалаштырырга һәм әлеге методикаларны яхшы үзләштергән белгечләр әзерләп чыгарырга ясалачак.

Тәрҗемә серләренә төшенүчеләрдән ике телне дә камил белү сорала. Биредә мөһим тел мәсьәләләре күтереләчәк. Татар теленнән турыдан-туры инглиз теленә һәм киресенчә тәрҗемә практикасы булу каралган. Тәрҗемә теориясе ул – бер нәрсә, ә менә телне аңлап тәрҗемә итү – икенче.

– Кулына магистрлык дипломы алучылар арасында Авыл хуҗалыгы, Химия-технология институтыннан, икътисад, мәдәният буенча белгечлек үзләштергән студентлар да бар. Быел да сорап, белешеп килүчеләр арасында үзбезнең рус филологиясе бүлеген тәмамлаучылар да, Мәскәүдән химия университетында укучылар да, Оренбург һәм башка төбәкләрдән дә бар. Гомумән, татар теле белән кызыксыну, аңа тартылу арта, – ди Әлфия Юсупова.

Киләчәктә мәктәптә өлкән сыйныфларда магистр дипломы булмаган кеше укыта алмаячак дигән фикерләр йөри, фәндә үз көчләрен сынап, киләчәктә галим булырга теләүчеләр дә магистр баскычын үтәргә тиешләр.

Магистратура нәрсә бирә дигән сорауны әңгәмәдәшем болайрак шәрехләде: «Магистратура – югары белемнең икенче баскычы. Бакалавр программасында дүрт елда алган нигез белемне тагын да тирәнәйтү, үстерү, ныгыту йә бөтенләй башка юнәлештә тагын өстәмә белем алу, дөньяга карашны киңәйтү. Ә алган белемне тормышка ашыру, гамәлдә файдалану ул кешенең үзеннән тора».

**Раил САДРЕТДИНОВ,**
КФУ студенты.

## Татарстан мөфтие:
# «Коръән укыган өчен гонорар сорамадым»

**«Хозур» нәшрият йорты, «Азан» радиосы белән берлектә, Коръәни-Кәримнең тулы аудиоязмасын яздырды. Аудио Коръән ике дискка яздырылган.**

Изге китапны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин укыган. Мөфти Коръәнне аудиоязма форматында эшләүчеләрнең – иң тәүгесе. Әлегә кадәр Россиядә бер мөфти дә әлеге эшкә алынмаган. Камил хәзрәт сүзләренчә, бу хезмәтне әзерләү ансат булмаган. Аны бер-ике айда әзерләп бетерергә ниятләгән булсалар да, эш сигез айга сузылган.

– Коръәнне берничә тапкыр укып яздырырга, киткән ялгышларны төзәтергә туры килде. Россия ислам институтына укытырга килгән Бөтендөнья Коръән-хафизлар әзерләү оешмасы вәкиле Хәсән Хәдиянең дә ярдәме зур булды. Аның Казанда булуыннан файдаланып, Коръәнне аудиоформатта яздыру эшенә алындык. Хәсән Хәдия күзәтчелегендә эшне бөтен таләпләргә туры китереп, ахырына кадәр җиткердек. Тавыш өзелгән чаклар да булды, мин хәзер артистларның хәлен аңлыйм инде. Тавыш өзелмәс өчен, юкә кайнатып эчәргә киңәш иттеләр, аның файдасы да булды, – диде ул «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында.

Журналистлар мөфтидән Коръәннең аудиоязмасын әзерләү ничә сумга төшүе белән дә кызыксынды.

– «Хозур» безнең нәшриятыбыз, ә Коръәнне мин укыдым. Аның өчен гонорар сорамадым, – дип шаяртты ул.

Коръәнне күчереп бастырырга теләүчеләргә файлларны бушка бирәчәкләрен дә әйтте.

– Аллаһ ризалыгы өчен башкарылган эш өчен акча соралмый, – ди Камил хәзрәт.


Коръән бер мең тиражда басылган, аның күпмедер өлешен бушка таратачаклар, калган өлешен «Хозур» нәшрияты кибетләреннән сатып алырга була.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

ФОТОГАЕПЛӘҮ

# Аңлаган кеше «туләсен»

Казан урамнарында татар телендә язылган игълан-белдерүләрне күреп, сөенәбез. Татарстан башкаласы иканлеге күренеп тора дибез. Метрополитенның «Кәҗә бистәсе» станциясенә дә татарча белдерү куйганнар, имеш. Ни кызганыч, сүзләрнең дөрес язылышын җентекләп тикшерүче булмаган. Реклама хуҗалары «йөрүне» һәм «түләгез» сүзләрен, «йөруне» һәм «тулэгез» дип, дөресләп язарлар, шәт.



Дамир Бәдриев фотосы

# АКЫЛ ҺӘМ САКАЛ

**Ни өчендер, сакал турында сүз чыкса, кешенең тел очында шундук «акыл» сүзе өерелә башлый. Моңа бәлки, халык әйтемнәре дә сәбәпчедер инде (сакалы мең карыш, акылы бер карыш, мәсәлән). Ә бәлки, бу сәбәп түгелдер. Нәтиҗәдер. Ни генә әйтсәң дә, бала-чагага сакал чыкмый ич. Ул җитлеккән, беркадәр тормыш тәҗрибәсе туплаган, димәк, акыл җыйган кешегә чыга. Белмим, әмма сакал сүзен һәрвакыт акыл белән тәңгәлләштерергә тырышу бар. Югыйсә акыл белән сакалның бер уртаклыгы да юк ич инде.**



Марат КӘБИРОВ

Акыл ул бөтен кешедә дә бар. Артыгы белән. Кеше аны көч-хәл белән күтәреп йөри. Тик ничек кулланырга гына белми. Алай итеп, болай итеп карый. Эшкә ярата алмый. Тегеләй дә, болай да, тегеңә дә, моңа да күрсәтергә тырышып карый. Кызыгучы юк. Аптырагач, кешеләргә өләшергә тырыша. Алучы да юк. Чөнки башкалар да аның хәлендә. Акыл ул – ни кулланып, ни котылып булмый торган бер могҗиза.

Сакал бөтен кешедә дә булмый. Бөтен кешедә дә булмаганга күрә, аның кадере зуррак. Аны матурлап кисәләр, юалар, хушбуй сиптерәләр, яратып сыйпыйлар. Үзендә булмаганнар кызыгып карый. Сакал кешегә шундук абруй өсти. Абруйлы кешегә, әлбәттә. Үз даирәсендә. Хе…

Бер мәлне Салават Фәтхетдинов та сакал үстерде. Бу хактагы хәбәр яшен тизлеге белән бөтен татар дөньясына таралды: «Салаватның сакалы бар!» Гәзитләр шул хакта язды, урам-авыз сөйләде. Һәм хәтта моңа кадәр билетка акча җәлләүчеләр дә Салават концертына агылды. Җырын тыңларга түгел, сакалын күрергә. Һәм алар да хәбәр таратты: «Салаватның чынлап та сакалы бар икән бит! Үзем күрдем!» Бер карасаң, гади генә нәрсә бит инде. Юк. Салаватның сакал үстерүе көнүзәк мәдәни вакыйгага әйләнде. Моны күреп торган ваграк җырчылар үзенчә ачыш ясады: «Ничава сибә, сакал кешегә дан өсти икән ич!» һәм эстрада йолдызчыклары кемузардан сакал үстерергә тотынды. Һәм тамашачының ябырылып килүен, бу хакта матбугатның шаулашуын көтте. Һәм алар көткәннең берсе дә булмады. Өстәвенә, бөтен татар эстрадасын сакал күмеп китә дигәндә генә, Салават үзенекен кырып ыргытты. Халык тагын пыр туздымы: «Салават сакалын кырган! Ишеттегезме әле? Салават…» Эш, әлбәттә, сакалда түгел, Салаватта иде.

Сакалны үстереп тә, кистереп тә була. Акылны үстереп булмый. Үстерергә кирәкми дә. Аны кая куясың? Бәрәңге түгел – базда саклап булмый, кыяр түгел – тозлап булмый. Хет акча да түгел ичмасам, - банкка салыр идең. Сакал – йөз күрке. Ә акыл кешенең йөзенә чыкмый, акыл күренми. Хәтта кешегә бик күрсәтергә тырышсаң да – ахмаклыгың гына күренә, акылың түгел.

Сакал кешегә беркадәр серлелек тә өсти. Сакаллы кеше чынлап елмаямы, әллә авызын гына ерып торамы – аңлап булмый. Чөнки көчәнә-көчәнә елмаюсыман мимиканы тотып торучы мускуллары күренми. Гомумән, кичерешләрен сиздерәп кешенең йөзендә чагылучы күп нәрсәләрне каплап тора сакал. Шуңа ул беркадәр серлелек бирә.

Бу язмаларны мин «Сакаллы кеше язмалары» дип атадым. Бу, мөгаен, аларга беркадәр серлелек бирергә тырышу нәтиҗәседер. Югыйсә монда әллә ни шаккатырырлык вакыйгалар да, акыллы фикерләр дә, файда бирерлек, сабак алырлык башка нәрсәләр дә юк. Барысы да – һәркем көн дә күреп, кичереп торган, һәркемнең аяк астында уралып йөргән хәл-күренешләр турында.

Мондый нәрсәләрне «акыллы кеше язмалары» дип тә атап булмый ич инде. Ни әйтсәң дә, Карл Маркс хезмәтләре түгел. Аннан соң, «акыллы кеше» дигән төшенчә бездә бөтенләй көтелмәгән нәтиҗә бирә. Сакаллы кешене кичерәләр, ахмакны гафу итәләр, хәтта намуссыз кешене гафу итәләр, ә акыллы кешегә шундук шикләнеп карыйлар. Ул бер юньсезлек кылмаган килеш тә дошмани мөнәсәбәткә дучар була. Ким дигәндә дә, «тагын бер әрәмтамак» сыманрак кабул ителә. Ә минем сезгә дошман да, әрәмтамак та булып күренәсем килми.

Шулай итеп, алдагы саннарда – сакаллы кеше язмалары.

**Туган авыл, печән өсте, киерелеп печән чабуларның матурлыгы турындагы җырлар, шигырьләр бүген дә бик күп микән. Бәлки, бераз азая да төшкәндер инде, бәлки, мин генә белеп бетермимдер. Элегрәк алар күп иде. Һәм бик ачуга тияләр, шуңа күрә колакка да эленәләр, хәтердә дә калалар иде.**



# Печән исе…

Миңа егерме бишләр тирәсе. Авыл. Печән өсте. Отпуск беткәнче гектар ярымлык посадканы чабып, җыеп, абзарга кайтарып китәргә кирәк. Бөтен гомер урманда үтә. Авылда яшәгән туганлы, дус-ишле кешегә әллә ни авыр да булмагандыр инде – кул алмаш та эшлиләр, башка җаен да табалар. Ә сиңа, кыска вакытка гына ялга кайткан кешегә, җиде кат тиреңне чыгарырга туры килә. Чабып бетереп, чүмәләгә салып куйгач та ничек алып кайтырга белми йөрисең. Техника табу җайсыз иде ул вакытларда. Колхоз техникасы колхозда эшләүчеләр өчен. Шәхси техника кыйбат, әле анысына да озын чират. Ә сиңа эшне бетереп китәргә кирәк. Аптырагач, теге техникалы абзыйга печән чабышырга, ташышырга йөрисең – шул рәвешле бераз бәясе дә төшә, чираты да кыскара. Олы бер нужа иде инде, кыскасы.

Шуңа күрә, мин печән турында шигырь язган кешеләрне куралмый торган идем. Боларның барсын да бергә җыеп, авылга алып кайтып, берәр атна печән чаптырасым килә иде. Кызганычка каршыдырмы, бәхеткә каршымы, алай кыланырга насыйп булмады. Күпләре өлкән яшьтәгеләр иде. Яшьрәкләре дә бик атлыгып тормыйлар. Авылда туып-үскән кешеләр ич инде. Авылда туып, бөтен авырлыкны күреп үсеп вакытында чыгып качкан кешеләр. Шуңа күрә, авылны сагынуның бөтен рәхәтлеген татып, шәһәрдә яшәүне хуп күрәләр.

Аларны авылга алып кайтып печән чаптырырга дию «Киерелеп печән чабам…» – рәвешендәге шигырьләргә ачу килгәннән генә иде инде. Югыйсә посадкада, агач арасында бик киерелеп чабып та булмый. Аптырау, гаҗәпләнү дә көчле иде. Ничек инде печән чапкан чакны сагынырга, шул хакта шигырь язарга мөмкин?!. Мин моны берничек тә аңлый алмый идем. Монда икенең бере генә була ала: йә боларга печән чабу тиешле дәрәҗәдә эләкмәгән, йә аз гына кыланалар, үзләрен эшчән, булдыклы итеп күрсәтергә тырышалар.

Мин беркайчан да печән чабуны сагыначак түгел идем. Гомер буена болай печән чабып йөрү яклы да түгел идем. Мөмкинлегем булу белән, сатып алу җаен караячакмын. Хәтта чәнти бармагым да тимәгән килеш, печән үзе минем абзарга килеп өелергә тиеш. Минем бөтен хыял шушы иде. «Хе, кем сатсын инде печәнне!» – дип куйды бер дустым, бу хакта ишеткәч. Ул хаклы иде. Печәнне сатучы юк. Елларның төрлесен күргән авыл халкы былтыргыдан калганын да чыгарып түгәргә ашыкмый, аерым бер җиргә өеп куя – корылык-фәлән килсә дип, запас тота. Аннан соң, көтүдәге маллар саны да бишәр-алтышар йөз белән исәпләнә. Һәр кеше өчәрдүртәр баш сыер асрый дигән сүз. Шулай булгач, «печән сату, печән сатып алу»дигән сүз үзе үк юләрлекнең бер рәвеше булып тоела иде.

Ләкин бу хыялның чынга ашуын озак көтәргә туры килмәде. Заман да үзгәрде. Бик күп хуҗалыклар печәнне басуда үстереп, халыкка сатып бирә башлады. Бәясе дә әлләни кыйммәт түгел – бары тик ал гына. Мин дә үзгәрдем бугай. «Шундый вак нәрсә өчен үзеңне борчып тормабыз инде, күпме печән илтеп бушатыйк?» – диючеләр барлыкка килде. Ә бераздан инәй дә олыгайды, сыер асрамый башлады. Печән чабуның да, аны китертүнең дә кирәге калмады. Кайчандыр зарлана-зарлана үзем көйләгән чалгылар да келәттә ятимсерәп эленеп тордылар да кайсы кайда таралышып беттеләр. Әни таратып бетергәндер инде. Үземә кирәкмәгәч, кызыксынып, төпченеп тормадым.

Тора-бара печән турындагы шигырьләр дә колакка эленми башлады. Бәлки, ул хакта язучылар да азайгандыр, бәлки, мин генә игътибар бирми башлаганмындыр. Үз ихтыяҗларың белән бер уртак булмаган нәрсәләрне ишетмәскә, күрмәскә гадәтләнәбез ич.

Әле бер кич подъезд алдына чыгып утырсам – тирә-яктагы үләннәрне чабып ташлаганнар. Бар дөньяда хуш исле печән исе. Печ-чән ис-се!.. Йөрәк сулкылдап куйды. Тормыштан зарлана-зарлана печән чабып йөргән чакларны хәтерләдем. Бер икеләнүсез шул чакларга кабат кайтыр идем. Чабар идем печәнен. Тик бу юлы зарланмыйча гына.

Авылдагы дус шалтыратты.

– Сездә хәзер печән өстедер инде, – дим, әлегә хисләр тәэсирендә. Теге көлә:

– Заманнан артта калгансың син… Нинди печән өсте булсын инде… Хәзер печәнне сатып алабыз бит.

**Соңгы вакытта, шартлатулар, терактлар саны артып китте. Кызганыч, күбесен ислам дине, мөселман халыклары белән бәйләп күрсәтәләр. Үзен мөселман дип йөрүче кеше террорист була аламы? Әгәр Аллаһыга инанган адәмнең кешелеккә каршы кулы күтәрелсә, бу вәхшилекнең чыганагы кайда? Бераз шушы нәрсәләр турында язып карарга булдым, Раббым Үзе ярдәм итсен.**

# Дин исеме белән кан коюю дөресме?



**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
Түбән Кама мәчете
имам хатибы

## ГАДЕЛЛЕК

Иң элек Пәйгамбәребез вакытында булган бер вакыйганы искә төшерик. Бервакыт, Аллаһының илчесе кешеләргә мал өләшкәндә, аның янына ЗульХувайсира исемле кеше килә һәм: «Әй, Аллаһының илчесе, гадел бул!» – дип әйтә. Пәйгамбәр аңа: ***«Кайгы сиңа, әгәр мин гадел булмасам, тагын кем гадел булыр? Әгәр мин гаделлек кылмасам, син зур югалтуда һәм хәсрәттә булырсың»,*** – дип әйтә (Бохари һәм Мөслим риваяте.).

Әйдәгез, шушы вакыйгадан чыгып, үзебезгә сорау бирик: әлеге кеше тормыштан нәрсә эзли һәм нәрсәне таләп итә? Сөбханаллаһ, ул гаделлеккә омтыла. Кешенең гаделлек эзләве начармы? Әлбәттә, юк, гаделлек – диннең нигезе. Аллаһы Тәгалә: **«Гадел булыгыз!»** – диде («Мәидә», 8 нче аять).

Кешенең гаделлек эзләве куандыра, әмма, бу кеше үзе өчен билгеләгән «гаделлекне» Аллаһының сайлап алган илчесендә дә күрмәде. Аның гаделлекне таләп итүе безнең ише гөнаһлы кешеләрне генә түгел, хәтта ахыр пәйгамбәрне дә залим итеп күрүенә сәбәп булды. Тормышта гел шулай бит ул, кайберәүләр башта үзләренә «дини кыйммәтләрне» төзиләр, аннары, шуларны башкаларда тапмагач, дошман күрә башлыйлар.

Әллә бүген шундый «гаделлек» эзләүчеләр азмы җир өстендә? Бервакыт, тәхрирчылар мәчетләр буйлап йөреп, җомга намазларында торып: «Әй, имам, Аллаһыдан курык! Кая гаделлек?» – дип кычкырдылар. Ярый ла үзләре генә кычкырып калса, ә бит күпме кешеләрнең эчләренә шайтан: «Алар бит гаделлек эзлиләр. Коръән аятьләре, хәдисләр китерәләр», – дигән шикләр салды.

Газиз кардәшләрем, шайтанның мәкерләгеннән саклаңыгыз. Күпме кешеләрне шайтан мең төрле хәйлә-ялганнар аша җәһәннәм утына алып бара. Иң аянычы шунда, алар үзләрен җәннәт юлында дип уйлыйлар, әмма упкынга тәгәриләр. Галимнәребез әйтүенчә, шайтанның кеше күңеленә үтеп керү өчен ике ишеге бар, шулар аша шайтан кеше эченә керә һәм аны туры юлдан аздыра. Болар шөбһәтләр һәм шәһвәтләр ишеге.

Шәһвәтләр ишегенә килгәндә, Аллаһ һәркайсыбызга нәфес – МИН дигән нәрсәне бирде. Һәр нәфеснең яраткан шәһвәтләкләре бар: кеше ашарга-эчәргә ярата, матур тормыш, күңел ачуларны сөя. Шайтан һәр кешенең нәфесе яткан нәрсәләрне өйрәнеп, аңа шуларны тагын да зиннәтләп күрсәтә. Ахыр чиктә, күпләр нәфесләренә хуҗа була алмыйча, шул шәһвәтләргә чумалар, хак юлдан тайпылалар. Мәкерле шайтан кемнедер байлык аша аздыра, кемнедер башын хатын-кыз белән әйләндерә, кемгәдер югары урыннар, шөһрәт-дәрәҗә вәгъдә итеп, туры юлдан адаштыра.

Шайтанның икенче ишеге – шөбһәтләр, ул кешегә хак динне ялган, үзгәртелгән рәвештә күрсәтә, акны – кара, караны ак итә. Кайбер кешенең Аллаһыга ихласлыгы, диндарлыгы нык булып, ул шайтанны шәһвәт ишегеннән кертми. Андыйларны нишләтергә? Хатын-кызга исе китми, акчага алданмый, ихласлыгы ташып тора, Аллаһыга буйсынуны өстен күрә. Андый вакытта, шайтан аның Аллаһ ризалыгына омтылуын башка тарафка юнәлтә, диндә чиктән ашу, фанатизм, катылык, үзенә дә, башкаларга карата да кырыслык кебек сыйфатларны булдырырга тырыша. Шулай итеп, шайтан кешедә булган көч-омтылышларны аның үзенә каршы юнәлтә.

## ЧИКТӘН АШУ

Кешедә «гулюу» – Аллаһы сызган чиктән ашу барлыкка килә. Шуңа күрә, Пәйгамбәребез безне бер яктан: шәһвәткә кол булып, шәригать кануннарына җиңел караудан кисәтсә, икенче яктан: дин тотуда гыйлемсез рәвештә хискә бирелүдән, чиктән ашып китүдән сакланырга чакырды. Пәйгамбәребез: ***«Гулюу – чиктән ашудан саклагыз, чөнки сезгә кадәр яшәүче күпме кешеләрне диннәрендә чиктән ашулары һәлак итте»,*** – диде.

Нәрсә ул гулюу? Гулюу – бер эштә артыклык күрсәтү, урталык һәм гаделлектән китү була. Хакыйкать – тәфрит (кимчелек кылу) белән ифратның (узып китү) уртасында булу белән генә табыла. Ашның тозы җиңел булса да, артыкка китсә дә тәме бетә. Табиб язган даруны чама белән эчсәң, сихәтлек табасың. Учлап авызыңа тутырсаң, агуланып үләсең. Һәр эшнең үз җае, үз чамасы бар. Чамасын белеп ашаган тәненә сихәтлек, көч ала, артыгын ашаганның хәле китә, авыруга сабыша. Чаманы белмәү һәр җирдә дә зыян китерә, хәтта диндарлыкта да. Аллаһыга инанган күпме кешеләрне шайтан шушы ысул белән хак юлдан тайпылдыра. Галимнәребез: «Аллаһ кешегә нинди генә әмер бирсә дә, шайтан аңа ике коткының берсе белән килә: яки аны чиктән аштыра, яки, киресенчә, әмергә җиңел карата», – диделәр.

Көймәң алга барсын дисәң, уртадан барырга, ярлардан ераграк торырга кирәк. Аллаһы Тәгалә: **«Сезне уртадан баручы өммәт иттек»,** – диде («Бәкара», 143нче аять).

## ЧИКТӘН АШУНЫҢ ЗАРАРЛАРЫ

Гулюу – диннең асылын үзгәртүче бер хорафат булып тора. Наданлыгы сәбәпле диндә чиктән ашып киткән кеше күпме кешеләрне нәфрәтләндереп, диннән ерагайта. Аллаһының дине тормышларны җимерү, болай да мәшәкатьле булган тормышны тагын да авырайту өчен түгел, ул яшәешне төзекләндерү һәм җиңеләйтү өчен килде. Пәйгамбәребез үз сәхабәләрен төрле халыкларга җибәргәндә, аларга: ***«Кешеләрне сөендерегез, нәфрәтләндермәгез, җиңеләйтегез, авырайтмагыз»,*** – дип нәсыйхәт кылган.

Сөекле Пәйгамбәребез иман ияләренә Аллаһының сынаулары киләчәген әйтте, әмма ул сынауларны ясалма рәвештә китереп чыгаруны тыйды. Бервакыт, пәйгамбәр бер кешене күрә: тегесе кояш астында басып торырга, сөйләшмәскә һәм ураза тотарга вәгъдә иткән. Пәйгамбәр аңа күләгәгә керергә, утырырга, сөйләшергә һәм уразадан чыгарга куша (Бохари җыентыгында). Кемдер: «Ул бит вәгъдә биргән, ә вәгъдә иман», – дияр. Мәгънәсез вәгъдәләр белән тормышны авырайтырга кирәкми. Бер олыгайган бабайны шулай ике улы култыклап мәчеткә алып киләләр. Пәйгамбәр: «Ник аны атка утыртмыйлар?» – дип сорагач, аңа: «Ул Аллаһыга җәяү йөрергә, атка атланмаска вәгъдә иткән», – диләр. Пәйгамбәр: «Аллаһыга аның үзен газаплавы кирәкми, атка утырсын», – ди (имам Мөслим китабыннан).

Күп вакытта, без диндә үз өстебезгә кирәкмәгән йөкләрне алабыз. Сишәмбе көн эш башлау хәерле түгел икән, корбан итенең сөякләрен ташларга ярамый, күмәргә кирәк икән, юлга чыккач, кире борылсаң, юлың уңмас, тырнак-чәчләрне яндырырга кирәк кебек тузга язмаган күпме хорафат белән баш катырабыз, тормышны авырайтабыз. Кеше үзенең намаз укучы кардәшенә кунакка килә, табын артына утыргач: «Ә итегез хәләлме соң? Аны кем суйган?» – дип сорарга тотына. Кайберләре намаз укучы аналарына кунакка килгәндә дә, үз ризыкларын күтәреп килә. Шиһабетдин Мәрҗани берничә хәзрәт белән пароходта Казаннан Уфага барганда ресторанда балык әзерләп бирергә сорый. Бер бетлесе шыпырт кына пешекчене күзәтергә китә. Ризык килгәч, тегесе: «Хәзрәт, мин пешекчене күзәтеп тордым, ул балыкка нидер салды, аның хәләллеге шикле», – дия. Шиһап хәзрәтләре: «Син күрдең, сиңа хәрам, ә без күрмәдек», – дип әйтә дә тегене балык ашатмый. Үзенең «ЭльБәрк эльВәмид» китабында ул янә шундый хикмәтле мисал китерә: «Гали ибн Хөсәен (пәйгамбәрнең оныгының улы) йомыш үтәү урынына кергәч, анда күп кенә чебеннәрнең башта нәҗескә, аннан аның киеменә кунуларын күрә. Бераз уйланып торгач, ул хаҗәт үтәү урынына керү өчен аерым кием булдыра. Соңыннан бу эштән Аллаһыга тәүбә итә һәм: «Мин сәхабәләр дә кылмаган эшне эшләдем, бидгать кылуда хәерлелек юк», – дип әйтә.

Бүген кайбер мәчетләрдә яшь кардәшләребез навигатор, электрон компаслар белән мәчетләрнең кыйблаларын тикшерәләр һәм: «Бу мәчетнең кыйбласы дөрес түгел», – дип, шау-шу чыгаралар. Яки мәчеткә йөрми башлыйлар, яки келәмнәрне борырга тотыналар. Сөбханаллаһ, сәхабәләр җирнең төрле илләренә барып, анда мәчетләр күтәргәннәр, кесәләрендә электрон компаслары да, затлы айфоннары да булмаган. Галимнәребез: «Кыйбланы билгеләгәндә, төгәл Мәккә шәһәренә түгел, Мәккә тарафына юнәлү тиешле», – дип әйтәләр. Замана җиһазлары күрсәткән тарафтан 20, 30, хәтта 45 градуска кадәр ялгышлыкны да проблема итеп күрмиләр.

Пәйгамбәребез: ***«Дөреслектә бу дин җиңеллектер, әгәр берәрсе динне авырайтса, дин аны җиңәчәк»,*** – диде. Ибн Хәҗәр бу хәдискә аңлатма биреп әйтә: «Хәдиснең мәгънәсе: кем дини эшләрендә кирәгеннән тыш тирән төшсә, йомшаклыкны югалтса, ул кешенең хәле бетәчәк, барган юлы өзеләчәк һәм ул җиңеләчәк».

→ **Ахыры киләсе җомга санында.**

# Китап киштәсе… подъездда

**Беркөнне машинада барганда радиодан бер мәзәк ишеттем. «Китапханәчеләр, көннәр эссе булганга, эш урыннарында шыр ялангач утыралар икән. Олырак яшьтәге берсе: «Кеше керер дип курыкмыйсызмы?» – дигән, яшьләрнең бу эшен өнәмичә. Тегеләре: «Китапханәгәме?! Беркем дә кермәгәнен үзең дә беләсең бит!» – дип, кычкырып көлгәннәр, ди. Дөрес сүзгә җавап юк. Ә минем бу мәзәктән, нишләптер, бер дә көләсем килмәде. Әйе, елмаерга түгел, еларга кирәк ич монда.**


Автор фотосы

**Йолдыз ШӘРАПОВА**

Ни хәл итәсең, ачы булса да, хакыйкать. Безнең ил соңгы елларда иң күп китап укучыдан иң күп китап укымаучыга әйләнә бара. Без моны барыбыз да белеп, күреп, сизеп торабыз. Ләкин ни эшләргә дә белмичә, бәлки, теләмичә дә, шуңа риза булып, күз йомып яши бирәбез. Чүплектә тау булып өелеп яткан китаплар яныннан тыныч кына үтеп китү дә безгә берни тормый.

Французларның бер мәкале бар: «Караңгылыкны сүгеп яшәгәнче, бер шырпы булса да кабыз», – диләр алар, акыллы киңәш биреп. Башкалабызның Восстание урамындагы 43 нче йортта яшәүчеләр дә бу мәкальне белгәннәр, күрәсең. Алар бүтәннәргә кушылып: «Хәзер халык китап укымый инде», – дип лаф орып утырмаска, ә ничек булса да, бу белем хәзинәсе белән дуслаштыруның юлларын табарга булганнар.

Бүгенге заман кешесенә иң җитмәгән нәрсә ул – вакыт. Атналар-айлар күз ачып йомган арада тарихны тулыландыра бара. Күпләрнең китапханәгә барып яраткан авторын бик укыйсы килсә дә, моның өчен вакыты җитмәскә мөмкин. Шуңа күрә дә бу подъездда яңа акция башлап җибәргәннәр – китапларны укучыга мөмкин кадәр якынайтып, ишектән керүгә үк стенага киштә ясаганнар. Анда бу йортта яшәүчеләр өй китапханәләреннән үзләре кайчандыр яратып укыган китапларны алып килеп, тезеп куйганнар. Мөхәммәт тауга бармаса, тау үзе аның янына килә. Монда да шулай булган.

Бу эшнең башында «Татарстан командасы» хәрәкәте әгъзасы, шушы йортның совет рәисе Светлана Карпухина тора.

– Без республикабызны башка регионнар арасында мәдәниятлерәк, зыялырак итеп күрергә телибез, бу башлангычны да шуңа оештырдык, – ди ул.

Буккроссинглы (китапны алмашып уку шундый модалы сүз белән атала хәзер) дүртенче подъездның башлыгы һәм йорт советы әгъзасы Леонид Лопухов та үзләренең бу эшләренә йортларының башка подъездлары да, аннары башка урамнар да һәм бөтен Казан кушылыр, дип өметләнә. Ул чагында, чынлап та, башкалабыз башка шәһәрләргә үрнәк күрсәтер һәм илебезне китапка кабат якынайтуда беренче адымны без ясадык дип горурланырга да җай чыгар.

Мин бу чарага журналист буларак җибәрелгән идем. Ләкин күңелемдә язучылык-шагыйрьлек тә яшәгәнгә, гомер буе китапка изге итеп карагангадыр инде, бу йортка буш кул белән килә алмадым. Үземнең ике телдәге ике төрле китабымны шул киштәгә куеп калдырдым. Автор өчен иң зур шатлык - китабының укый-укый теткәләнеп беткәнен күрү. Кулым җиңел булсын! Киштәләрдә – китаплар, аны укучылар саны да артып торсын.

# Хуҗасызлык

Лаешта булганыгыз бармы икән? Дөньяның иң гүзәл почмакларының берседер ул, мөгаен! Юл уңае булса, кагылып китегез әле бер бу шәһәргә. Чулман яры буйлап калкулыкка таба бер-берсенә параллель урнашкан урамнарның һәр йортындагы капка төбенә чыгып бассаң, каршында изрәп иксез-чиксез «диңгез» ята. Җилсез, аяз матур җәй көннәрендә, бу күренешне әллә нинди ял йортлары белән беррәттән куеп булыр иде. Кояш нурлары күзләрне җиңелчә генә чагылдыра. Шул нурлар астында бар нәрсә дә ялтырый кебек. Өйләр дә, алар янындагы гөлгә, җиләк-җимешкә күмелгән бакчалар да, эреле-ваклы кибетләр, чиркәү дә. Хәтта берәм-сәрәм генә, җәяүләп ашыкмый гына эшкә баручы, каршыга очраган кешеләр дә нурлы кебек. Кыш көнен күз алдына китерегез: каршыңда ап-ак чиксезлек, зәңгәрсу күгелҗем булып кар ялтырый. Көзге яңгырлар вакытында да диңгез үзенең муллыгы белән, көчле шаулавы белән йөрәккә дәрт-дарман биреп тора. Яз җитсә, боз киткәнен көтәсең, хозурланып күзәтәсең. Үзе бер манзара, үзе бер табигатьнең яңарышы, кардан, боздан әрчелеп яңадан тууы кебек.

Лаеш үзәгендә күбрәк шәхси йортлар булгангадыр, ул йортларның һәр капкасы, һәр коймасы таныш. Бакчалары бигрәк тә. Үзәккә тротуар буйлап төшкәндә, уннарча бакча яныннан узасың. Миңа шәһәргә керә торган юл буендагы бер бакча аеруча ошый. Башта өеннән үк башлыйм әле. Пасха бәйрәме җитүгә, өйне тышыннан ук ялтыратып куя хуҗа апаң: акшарлыйсын акшарлый, юасын юа, җыясын җыя. Урыннарын белеп утыртылган алмагач, чия, карлыган һәм башка җиләк-җимеш агачлары карала башта, аннары матур итеп түтәлләр ясала. Иң соңыннан помидорлар шул чаклы тәртип белән утыртыла, таякларга бәйләп тә куела.

Чәчәк түтәлләре бер-бер артлы гөлгә күмелә: башта лалә белән нәркисләр, аннары утчәчәк белән лилияләр, аннары инде бик күп сандагы аллы-гөлле чәчәкләр октябрь азагына чаклы бакчага ямь биреп утыра.

Узган җәй бакчаны караучы булмады. Миннән дә озынрак чүп үләннәре горур басып, «нәрсә безгә карыйсың?» дигәндәй, көзгә урманга әйләнде. Кыш көне өйгә керә торган тар гына сукмак күргәч, мин әлегә җан иясе бар икән монда дип язны көттем. Яз җитте, өметләрем акланмады. Тәрәзәләре ватылып беткән, ишеге шыр ачык өйне шыксыз, корыган үлән сабаклары урап алган иде. Хуҗабикә апам бакыйлыкка күчкән икән дип, юксыну хисләре белән уздым өй яныннан. Бакча да, өй дә ятим калган…

**Гөлфия СОЛТАНОВА.**

**Казан урамнарында тезелеп торган шәрык кафеларына кереп ашарга яратам дип әйтә алмыйм. Шулай да кайчакта кереп тамак ялгап чыгарга туры килә. Бу юлы тик торганнан гына керергә булдым. Әллә чакрым ярымга кадәр таралган кызган ит исе башны бутады, әллә чыннан да ашарга кирәк булдымы… Ишегенә хәләл дип язылган. Бу сүз, телисеңме, теләмисеңме, күңелдә ышаныч тудыра. Ярар, Аллага тапшырган.**

# Дивана

Кафеда кеше күп түгел, өстәлләр чиста күренә. Мин заказ ясадым да читкәрәк барып бастым. Исәбем монда ашау түгел, юлда гына капкалап алу. Мин көткән арада, зур гына корсаклы, кара кашлы бер абзый кереп пылау сорады. Ул да өстәл артына барып утырмады. Көтәбез. Заказларны кабул итүче хатын выж-выж гына өстәл сөртә. Кинәт кенә эчке яктан ризык алып чыгып килүче пешекче иргә килеп бәрелде. Тегесе чайкалып китте: «Дивана, нишлисең! Карабрак йөр!» – дип, хатынга кычкыра да башлады. Кысык кара күзле бу хатын оялып китте, кызарып чыкты. Безгә карап гафу үтенде. Минем яндагы абзый:

– Ярар, нәрсәгә гафу үтенеп торасың, була торган хәл, – диде. (Сөйләшү рус телендә бара.)

– Менә бит миңа әшәке сүз әйтте, дивана дурак дигән сүз бит, шуңа кыен булып китте, – диде хатын.

–И-и, бу сүзнең тәрҗемәсен миңа әйтеп тормасаң да була, мин бит әзәрбайҗан, төрки кешесе – сезнең телне аңлыйм. Кыргызчаны да, башкаларны да.

– Мин – кыргыз, ә ул – үзбәк, –дип баш селкеде хатын пешекче ир ягына.

– Ә сез кем? – диде абзый, миңа карап.

– Мин татар, – дидем.

– Алайса, без барыбыз да бер-беребезне аңлыйбыз, – диде хатын.

–Шулай шул, – дидем, – ә гафуны сез түгел, сезгә дорфа сүз әйткән ир кеше сорарга тиеш булгандыр, – дип тә өстәдем. Тегесе ишетмәмешкә салынды.

– Алар шулай, өйләнгәнче генә хатын-кызга, Омар Хаям язганча, мин сиңа дивана кебек гашыйк дип тасма телләнәләр, аннары, бер ел үтәме, юкмы, хатын-кыз диванага әйләнә дә куя. Ике сүзнең берендә, кирәкме-юкмы, дивана да дивана. Ярый әле тагын да әшәкерәген әйтмәсәләр.

–О, Омар Хаям, менә ул шагыйрь булган! Аны мин укып туя алмыйм, мөгаен, ул әзәрбайҗан булгандыр, – дип сүзне икенчегә борып ялгап алды кара кашлы абзый.

Караңгы чырайлы пешекче үзбәк тә телгә килде:

–Юк, мин төгәл беләм, ул үзбәк булган.

–Ә бәлки кыргыздыр?

Аларны юатыр өчен бу шагыйрь борынгы гомумтөрки әдәбият вәкиле дип әйтәсем килсә дә, дөресен әйтергә булдым:

–Кызганыч, җәмәгать, әмма Омар Хаям фарсы әдәбиятының якты йолдызы, таҗик. Ә алар төрки түгел.

Яңа танышларым авыр гына көрсенеп куйдылар.

– Әй, без аны барыбер яратып укыйбыз, әнә Путинның да өстәл китабы икән аның робагыйлары, – дип сүзне төгәлләде пылавын көтеп торучы абзый кеше.

**Айсылу ИМАМИЕВА.**

Бөтен кызыклы
мәгълүмат
бер урында
www.shahrikazan.com

ДЕНЬГИ ВСЕМ
Гарантируется получение денег
с любой кредитной историей
с 21 до 55 лет.
8-927-244-22-77, 8-937-003-55-00.
ООО «МК «Альтернатива» ОГРН 1131690081709 Реклама

# БЕР КИТАП ТАРИХЫ

**Тукай, халкын олылап, милләт өчен борчылып язган әсәрләре белән генә түгел, ә һәр гади кешегә дә аңлаешлы өр-яңа әдәби телгә нигез салуы белән дә тарихка кереп калган шәхес. Аның беренче китаплары гарәп графикасы белән басыла, тиражы да әллә ни күп булмый.**









Нинди бәхет: шул үлемсез китапларның бер нөсхәсе минем кулыма да килеп керде. Аны миңа Төбәкне өйрәнү музееның штаттан тыш хезмәткәре, Югары Кыерлыда яшәүче Нуретдин Имамиев биреп торды. Китап аңа очраклы гына килеп ирешә. Инде узган гасырның 80нче елларыннан бирле тарих белән кызыксынучы, төрле иске китап, документлар җыючы якташыбыз 2013 елда Киров өлкәсенең Сосновка шәһәрендә яшәүче туганнан туган сеңлесе Роза янына кунакка бара. Роза аңа 60-70нче елларда Сосновкада мулла булып эшләгән, 1906-1992 еллар аралыгында яшәгән әтисе Салихҗан Шакирҗановтан калган бер китапны күрсәтә. «Кечкенә вакытта озын кичләрдә, әти гел шул китаптан төрле шигырьләр, әкиятләр укый иде. Без Тукай әсәрләре белән тәрбияләнеп үстек», – ди. Тик китапның аңа ничек килеп эләгүен әйтә алмый. Салихҗан бабай Тукай китабын күз карасыдай саклый, кызына да кадерле ядкарь итеп тотарга кушып калдыра.

Китап кулыма эләгүгә, миндә күп сораулар туды: кайчан басылган, нинди шигырьләр кергән, ничек Сосновкага барып эләккән? Сорауларыма бераз ачыклык кертү өчен, шәһәребез мәдрәсәсенә киттем. Ярдәмгә Мамадыш мәдрәсәсендә директор урынбасары булып эшләүче Ранил Талипов килде.

Китап Габдулла Тукайның әсәрләр җыелмасы булып чыкты. Ул 1914 елда Казанда чыккан. Китапның титул бите төшкән, күрәсең, кулдан «Атаклы шагыйребез Кушлавыч авылының Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаевның Мәҗмугаи асаре» дип язылган. Алгы битенә Тукайның 1910 елда төшкән, сирәк очрый торган фотосурәте куелган. Аңа шагыйрь үз кулы белән «Кыйтга» (1913) шигыреннән бер өзек язган:

*Кайтмады уч, бетте көч,*
*сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем,*
*дөньяны пакьли алмадым.*

Китапта шулай ук Тукайның үләр алдыннан төшкән фотосурәте дә урын алган.

Китап авторның үзе турында язган «Исемдә калганнар»ы белән башланып китә.

«Су анасы», «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык», «Бала белән Күбәләк», «Пар ат», «Эш беткәч уйнарга ярый» кебек күп кенә әсәрләренә күләмле булмаган рәсемнәр ясалган. «Су анасы»н шагыйрь 1908 елда яза һәм «Бер авыл малае авызыннан» дип билгеләп китә, димәк, ул аны элегрәк халык авыз иҗаты белән кызыксынып авылдан авылга йөргәндә ишеткән. Шулай ук Тукай «Пар ат» шигырен Лермонтовның «Тройка»сын укуы тәэсирендә язганлыгын әйтеп үтә.

Танылган әсәрләре белән беррәттән, «Ишек бавы», «Гашыйк», «Авыл хатынының бала тирбәткәндәге өмитләре», «Васыятем» кебек күп әсәрләре дә кергән. «Проповедь» («Вәгазь») шигыре русча бирелгән һәм Абдулла Тукаевтан дип язылган.

Мин Ранил хәзрәттән бу әсәрләрнең бүгенге тексты белән ул вакытта, чын Тукайча басылуы арасында аерма бармы икәнен һәм телче буларак бәяләмә бирүен сорадым.

– Әчтәлеге, текст язылышы шул ук, – диде ул, - тик кайбер сүзләр искечә язылган. Мәсәлән: моны-боны, ачты-ачры, суккалап-сукгалап, шатлык-шадлык, җирем-йирем һ.б. гарәп, фарсы теленнән кучкән алынма сүзләр.

Китапны ничек әзерләве, китапка кергән әсәрләре өстендә ничегрәк эшләве турында Тукай «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсендә язып калдыра. Аны татар дөньясында бик популяр булган һәм шагыйрьнең һәр язылган шигырен чыгарып барырга тырышкан «Кояш» газетасы 1913 елның 18 март санында бастырып чыгара. «Тиз арада үзем браковать итмәгән һәм үзем яраткан шигырьләрдән җыеп 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем», – дип яза Тукаебез…

Ул ашыга, кабалана, ни өчен дигәндә, 1913 елның ел башыннан, бераз чигенеп торган авыруы көчәеп китә (туберкулезның соңгы формасы) һәм шагыйрьгә дуслары тизрәк дәваланырга кереп ятарга кушалар. Аерым-аерым басылган шигырь, әсәрләрен бербөтен басма итеп күрергә хыялланган шагыйрь бу эшне Клячкин хастаханәсенә керер алдыннан төгәлләргә тели. Ялгыз эшләү аның сәламәтлеген начарайта, болай да хәлсез организмының соңгы көчләрен ала. «Ике-өч төн йокламыйча, мәҗмугаи асаремне тәртипкә салдым, шул мине бөтенләй эштән чыгарды», – дип сөйли ул хастаханәгә хәлен белергә килгән дусты Шиһап Әхмәровка. Хастаханәдән дәваланып чыгарга, бераз булса да яшәргә өметләнгән Тукай китабын аннан чыккач та бастырырга уйлый. Шуңа күрә, язган мәкаләсен дә «Уянгач беренче эшем» дип атый, ягъни терелеп чыккач та беренче эше итеп, үз куллары белән тупланмасын чыгарырга тели. Ни кызганыч, ни үкенеч: кечкенәдән салкын тидереп үпкә авыруыннан интеккән, җирсез, өйсез, гаиләсез, салкын бер номерда яшәп, көнен-төнгә ялгап иҗат итүче Габдулла Тукай көннән-көн сула бара. Клячкин хастаханәсенә 10 мартта (искечә – 26 февраль) кереп яткан шагыйрь 15 апрельдә (искечә 2 апрель) инде дөньядан китә…

Габдулла Тукайның «Мәҗмугаи асаре»н – ягъни, үзе әзерләп калдырган беренче тупланмасын XX гасыр башының танылган галиме, тел белгече, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, Тукайның дусты Җамалетдин Вәлиди 1914 елда 463 битле итеп туплап, үзенең кереш сүзе белән, Казанның Шәрәф типографиясендә бастырып чыгара. Ул әллә ни үзгәрешләр кертми: Тукай әзерләгән әсәрләргә рәсемнәр өстәлә, шагыйрьнең берничә фотосурәте куела. Вәлиди басманы тизрәк дөньяга чыгарырга тели, ник дигәндә, шагыйрьнең үлеменә бер ел була һәм ул шул рәвешле дустының хыялын тормышка ашырырга уйлый. (1918 елда шул ук автор тарафыннан икенче басма дөнья күрә. Монысында «Исемдә калганнар» повесте «Алтын әтәч» поэмасы белән алмаштырыла. Кереш мәкаләдә һәм 1923 елда «Мәгариф» журналының 3-4нче саннарында басылган «Тукайның шагыйрьлеге» исемле хезмәтендә автор татар әдәбият белемендә шагыйрь иҗатын беренче мәртәбә чорларга һәм жанрларга бүлеп тикшерә һәм әдипнең гыйльми биографиясен тудыруга нигез сала. Кызганыч, гасыр башындагы күп кенә әдипләребез, галимнәребез кебек үк, Вәлиди дә репрессия корбаны була).

Китап, басылышыннан башлап, кем кулында гына булмаган. Бу турыда бит кырыйларына язылган искәрмәләрдән күреп була: мәсәлән, Казанда яшәүче Гыйлемхан, Илдархан (төгәл адреслары бар), Айдарово авылында яшәгән Давлетшин Гәрәйша, төрле шәһәрдән Сафин, Айдарова һ.б. Башта аны Казанда 45 сумга сатып алганнар, аннан төрле елларда бәя төрлечә булган: 1947 елда кемдер 2750 сумга сатып алган, 1948дә – 3800, ә 1951 елда бәя 6550гә җиткән. Бер битендә 1951 елның 20 гыйнварында гарәп хәрефләре белән мондый сүзләр язылган: «Мин бу китапны укыдым. Бик яхшы китап! Укымаган кешегә укырга кушам. «Укы, гыйбрәт ал».

Китапның безнең көннәргә ертылмыйча, чагыштырмача чиста килеп җитүе хуҗаларының аңа чынлап та ядкарь итеп, Тукайның мирасы итеп караулары күрсәтә. Рәхмәт аларга!

**Гөләндәм ДАВЫДОВА,**
Мамадыш районының төбәкне өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре .

# Син Казан Кремле өченме?

Казан Кремле сурәте чын-чынлап 200 сумлык акчага басылсын дисәң, бүген, ягъни 5 август көнне 18.00 сәгатьтә Кремль яр буенда узачак фестивальгә кил. Ул көнне #200казань хэштегы берләштелгән шәһәр җанатарларын осталык дәресләре, экстрим-шоу, җанлы музыка, КВНчылар, «Голос дети» проектында катнашучылар белән бергәләп күңел ачу программалары көтә.

Нәтиҗәдә Казан Кремле өчен ни кадәр кеше тавыш бирүен 200 сумлыклар белән бизәлгән «Акча агачы» һәм фестиваль тәмамланганда күккә очкан шарлар күрсәтеп торачак.

# Башкалада 200 сумлык акча кулланышка керде

**Казанда яңа 200 сумлык кәгазь акчалар кулланышта йөри башлады. Яңа төр банкнотлар рәсми төстә чыгарылмаса да, алар белән Казан Кремле территориясендә урнашкан мәдәни учреждениеләргә керергә мөмкинлек тудырылды.**

Казан Кремле Россиядә беренчеләрдән булып, яңа үрнәктәге акчаларны тест режимында сынап караучы территория булды. Биредә урнашкан музейларга беренче августтан бишенче сентябрьгә кадәр 200 сумлык сувенир кәгазь акчаларны «түләп» кереп булачак. Аларны исә #200казан акциясе кысаларында алырга мөмкин. Инде алдагы көннәрдә сувенир акчалар белән музей экспонатларын карарга керүче кешеләр саны шактый арткан һәм аларның берсе дә кире борып чыгарылмаган.

Әлеге «кәгазь акчалар» белән керү өчен ишекләре ачык булган мәдәни учреждениеләр исемлегенә Татарстанның Табигый тарих, Ислам мәдәнияте, Татарстан Милли музее, «Казан-Эрмитаж» үзәге, «Манеж» күргәзмәләр залы, Тупчы сарае һәм Благовещенск соборы тарихы музейлары кертелгән.

Исегезгә төшерәбез, үткән ял көннәрендә шәһәрнең биш мәйданында «#200казан» хэштегы белән Казанга теләктәшлек белдергән һәр кешегә сувенир акчалар таратылган иде. Бу купюралар Казан Кремлендәге барлык музейларга бушлай керү мөмкинлеген бирә.

Әлеге акция бу көннәрдә социаль челтәрләрдә актив казанлылар, Россиянең танылган блогерлары, музыкантлар, спортчылар һ.б. танылган шәхесләр ярдәме белән зур популярлык алган флешмобның бер өлеше булып тора. Флешмобта катнашучылар Казан Кремле һәм махсус стенд-купюралар янында фотосурәткә төшеп, аны #200казан хэштегы белән Инстаграмга элә. Хәзерге вакытта әлеге фотоЧелтәрдә 650 пост барлыкка килде, ә акциядә катнашучыларның саны 2,5 млн га җитте.

## УЗЫП БАРЫШЛЫЙ

**Поездда барганда Адыгея республикасыннан бер әби белән таныштык. 80 яшь үзенә. Шулай да курыкмыйча, бер ялгызы гына ерак юлга чыккан. Мари Эл республикасына туганнарына кунакка кайткан булган. Хәзер кире туган ягына кайтуы икән.**

# Һәркемнең үз чирәме

Беренче көнне үк туган җирен сагынып сөйли башлады ул.

Бер елны Мари Элга оныгымны да алып кайткан идем. Ул бөтенләй бер кич тә кунмады авылда. Казандагы кунакханәдә яшәргә туры килде. Мари Элдагы без кайткан авылда 8 чиркәү бар. Ә менә халык хәерчелектә яши. Өйләргә газ кермәгән, суны да чишмәдән ташырга туры килә, бәдрәфләр урамда. Яшүсмер оныгым, әлбәттә, бу шартларга түзә алмады», – дип сөйли әби. Хәер, Адыгеядә дә әби шәһәр фатирында тормый икән анысы. Кечкенә генә бер авылда яши. Сыеры бар, сөтеннән сыр ясап сата. Анда мондагыдан барыбер яхшырак, ди үзе.


– Улым каравылчы булып 40 мең сум акча эшли, бакчада үз коебыз бар. Пенсия дә бездә күбрәк түләнә. Әгәр дә ире үлеп китә икән, хатынының ай саен ире пенсиясен алырга хакы бар. Беркайда да эшләмәгән хатын-кызлар өчен бу отышлы. Шуңа да күпләр ирләре пенсиясенә яши, – ди әби.


Безнең күңелгә исә Татарстан авыллары – иң матуры. Нур бөркелә безнең салалардан. Мәчетле манаралары әллә кайдан балкып тора, алтындай арыш кырлары, ябалдашлары күлгә төшеп торган каеннар, тәрәз яңаклары бизәкләп эшләнгән йортлар, чәчәккә күмелгән ишегаллары дисеңме. Адыгеядән теге әби үзләрендә үсә торган «воробьевка, алыча»сын мактаганда, без үзебезнең бәрәңге буразналарын, алмагачлы бакчаларны күз алдына китереп бардык. Чирәм дә безнең якта башка төстә, матур яшел тоелды безгә. Һәркемнең үз чирәме, күрәсең.

**Эльвира МОЗАФФАР.**

# СКАНВОРД









Крейсер. Төн кошы. Актриса ... Лучко. Самолет. Рөстәм Сәрвәров студиясе. «...-Дамм де Пари» мюзиклы. Физикада тыгызлыкны аңлата. Мәркәз. Мәҗлестә теләкләрне теләп бокал күтәрү. Борынгы җилкәнле крейсер. Ульяновск автомобиле маркасы. Сусыл терлек азыгы. Канар. Биюдәге ритмик хәрәкәт. Кешедә алар 32 дәнә. Кызыл мәйданда хәрбиләр маршы. Супер очучы. Греция алфавитының 10-нчы хәрефе. 4047 м². Чегән кызы. Джерриның «дусты». Бик саран. Ультра кыска дулкын. Балалар язучысы Абдулла. Татарстандагы район. Тун футболкырында түгел. Кисәкчә. Мәркәзе – Бәйрут шәһәре. Иш, әшнә. Калын тыгыз кәгазь. Театрда тәнәфес. Салтыкова бала чакта. №85-нче химик элемент. Яктылык чыганагы. Исерек булмау. Ризык. «... Скала». Әкияттәге канатлы ат. Көчле җил. Хәрәкәт итү әгъзасы. Синтезның антонимы. Родари. Филиппиндагы вулкан. Элекке Горгиппия шәһәре. Татар хатын-кызлары исеме. Рус эстрада төркеме. Җәядән ату коралы. Африка дәүләте. Хөрмәт. Теркәгеч. Курчак. Мәркәзе – Солт-Лейк-Сити шәһәре. Әти кеше. «Кока-...». Җәнлек. Калашников автоматы. Гаскәрнең дошманга омтылышлы һөҗүме. Британия җырчы-музыканты Маккартни. Җырчы ... Закиров. Икмәк. Башкортстандагы район. Гогольнең комедияле пьесасы. Вертолет. Сәрви агачы.

Фаил Гаязов төзеде

**Горизонталь буенча:** «Аврора», лайнер, ябалак, силос, теш, утрау, акр каппа, карун, Апас, Аза, Ливан, астат, та, давыл, Апо, дус, Ира, ук, Мали, Такташ, «ДДТ», ата, Шамил, атака, аю, АКМ, Динарт, Пол, Бакалы, «Ревизор», ипи, акация.

**Вертикаль буенча:** антракт, тулпар, аяк, УКВ, Руслан, анализ, Алиш, Клара, кадер, парад, ки, «Аксу», ас, Джанни, тост, ут, «Нотр», аек, барби, «Акат», Юта, ро, «УАЗ», аут, Ка, па, Анапа, Том, «Кола», башкала, ашамлык, «Ла», Вадим, картон, Солтания.

## АФИША 8 АВГУСТ – 14 АВГУСТ

**«ХӘЗИНӘ» МИЛЛИ СӘНГАТЬ ГАЛЕРЕЯСЕ**
(КРЕМЛЬ)
**4 август-4 сентябрь** «Линия жизни» Юрия Филимонова күргәзмәсе
Башлана: **16.00**
Билет бәясе: **200 сум**

**УНИКС**
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2 ЙОРТ)
**9 август** «Собачье сердце» (М.Булгаков)
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **600-900 сум**

**ЦИРК**
(МЕҢЬЕЛЛЫК МӘЙДАНЫ, 2)
**11-14 август** «Эмоции и...» Абыйлы-энеле Запашныйлар циркы
Башлана: **18.00**
Билет бәясе: **500 – 1300 сум**

**КУРКАЧИ АЭРОДРОМЫ**
**12 август** «Мин күкне сайлыйм»
Башлана: **10.00**
**Керү ирекле**

**БОЛГАР ШӘҺӘРЕ**
**13-14 август** «Бөек Болгар» фестивале
Башлана: **11.00**
**Керү ирекле**

**ЛЯДСКОЙ БАКЧАСЫ**
**13-14 август** «Урам сәнгате фестивале»
Башлана: **11.00**
**Керү ирекле**

**«ШПИНАТ» КРЕАТИВ ЗОНАСЫ**
(ӘМИРХАН ЕНИКИ УРАМЫ, 17Б)
**13 август** «Про Степана казака...» курчак театры
Башлана: **11.00**
Билет бәясе: **300 сум**

**Г.КАМАЛ ТЕАТРЫ**
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)
**14 август** Салават Фәтхетдинов концерты
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **1000 – 1800 сум**

**ВАХИТОВ ПАРКЫ**
**13-14 август** «Open space market» Танылган дизайнерлар җыены
Башлана: **12.00**
Билет бәясе: **100 сум,** студентларга – **50 сум**
**(7 яшькә кадәр булган балаларга һәм пенсионерларга керү ирекле)**

**«MURZIK» КОТОКАФЕСЫ**
(ВОЛКОВ УРАМЫ 60/12)
**14 август** Песиләр белән йога
Башлана: **11.00**
**Керү 200 сум**

**ЗАМАНЧА СӘНГАТЬ ГАЛЕРЕЯСЕ**
(КАРЛ МАРКС УРАМЫ, 57)
**14 август** «Үткәннәрдән сәлам» Борис Давыдовның шәхси күргәзмәсе
Башлана: **10.00**
Билет бәясе: **50-150 сум**

**«ХӘЗИНӘ» МИЛЛИ СӘНГАТЬ ГАЛЕРЕЯСЕ**
**14 август** «Сабан туе»
Татарстан рәссамнарының 27 эше тәкъдим ителә
Билет бәясе: **200 сум**

**«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ**
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)
Татарстан Рәссамнар берлегенең Г.Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган күмәк күргәзмәсе
**Керү ирекле**
**(эш көннәрендә)**

**ГОРЬКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ҮЗӘК МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ЯЛ ПАРКЫ**
**14 август** «Яшел фитнес»
Башлана: **10.00**
**Катнашу ирекле**



Шамил Абдюшев фотосы

# Ренат Рәхмәтуллин: «Онык көтәм»



**Популяр җырчы Ренат Рәхмәтуллинның җәе ничегрәк уза икән? Шул турыда белешергә дип, автор-башкаручының үзенә шалтыраттык.**

– Әткәй, мәрхүм, ярый әле Аллаһы Тәгалә тәнне яраткан, ул булмаса, кеше эштән бер дә туктый белмәс иде, дип әйтә торган иде. Көне буе әле бер, әле икенче шәһәргә, авылга Сабан туйларына, концертларга йөргәндә гел шушы сүзләр колакта яңгырап тора. Кайткан арада яңа җырлар яздырам. Туйлар, бәйрәмнәр дә алып барырга күп чакыралар. 8-15 августта Пермь якларында сольный концертларым үтәчәк. Шул мәшәкатьләр белән дә чабып йөргән көннәребез.

Җәе булгач, бакча эшләре, вак-төяк ремонтлары да бар инде аның. Буадан берничә чакрым ераклыкта гына урнашкан Түбән Наратбаш авылында яшәүче әнкәй янына да көн дә кайтып йөрибез. Ул исән-сау гына була күрсен. Кечкенә кызыбыз Регина җәй буе аның янында. Менә әле дә лагерьдан кайтты да, тагын әнкәй янына авылга китте. Кызыбыз да бик матур итеп җырлый. Аны үзем белән бергә зур шәһәрләргә чыгыш ясарга да алам. Олы кызыбыз Ландышның кияүгә чыкканына ике ел. Әлегә бәбиләре юк. Оныкны бик көтәм инде. Кызым башта яхшы эшкә урнашам диде, менә хәзер эше дә булды инде, бәлки, онык белән дә озак көттермәсләр дип өметләнәбез.

Августның икенче яртысыннан соң ял итәргә планлаштырабыз. Мин чит илләргә барырга кызыкмыйм. Ял итәр өчен үзебезнең Россияне кулай күрәм. Быел Тоз күленә, Кырымга барырбыз дип торабыз, – дип, планнары белән уртаклашты җырчы.

**Зәһрә САДЫЙКОВА.**

## 11 мәзәк

Танылган галимнән сорыйлар:
– Ник сез галәмнән акыллы затлар эзләргә булдыгыз?
– Җирдән эзләп карадым инде.

* * *

– Сезнең ютәлегез миңа ошамый...
– Гафу итегез, доктор, ләкин яхшырак ютәлли алмыйм.

* * *

Ир белән хатын урамда сәйран кылып йөриләр. Хатыны:
– Чибәр кыз күргән саен, шундый итеп карыйсың, өйләнгән булуыңны бөтенләй онытасың!..
Ире:
– Киресенчә. Нәкъ шул исемә төшә.

* * *

– Җаным, ә син мине яратасыңмы?
– Яратам!
– Ә минем өчен гомереңне дә бирә алыр идеңме?
– Бирә алыр идем. Тик ул чакта сине кем ярату соң?

* * *

70 нче еллар, ерак төпкелдәге авыл. Ике бичә колхоз җыелышыннан кайтып баралар ди.
– Әйгенәм, ахиратәкәем, – ди берсе, – бу читтән килгән яңа персидәтел бигрәк явыз кеше икән лә!
– Нигә алай дисең?
– Бәй, димичә... «Авылыгызга ут кертәм, газ кертәм» дип курыкта бит!

* * *

Урамда.
– Әни, ә син сериаллар карарга яратасыңмы?
– Юләр сүз сөйләмә, Лукас, Җадины җитәклә дә атлавыңны бел.

* * *

Имтихан алдыннан.
– Дулкынланасызмы?
– Әй-йе...
– Беренче тапкырмыни?
– Юк, моңа кадәр дә дулкынланган бар иде.

* * *

Ике аучы аю эзенә юлыга.
– Гали, бар, син аю кайда киткәнен кара.
– Ә син?
– Мин аның каян килгәнен карыйм.

* * *

Вәли мәктәптән кайтып керә.
– Көндәлегеңне күрсәт, – ди әтисе.
– Мин аны Галигә биреп тордым.
– Ник?
– Әти-әнисен куркытыр өчен.

* * *

– Мин, әтием кебек, аена мең доллар акча эшләү турында хыялланам.
– Синең әтиең аена мең доллар акча эшлиме?
– Юк, ул да бу хакта хыяллана...

* * *

– Доктор, сез миңа, яшәсәгез тагын ике, күп дигәндә, өч атна яшәрсез, дигән идегез. Инде менә өченче ай китте, мин һаман да исән...
– Димәк, дөрес дәваламаганнар...



Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ). – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ДИРЕКТОРЫ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛЕВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843). 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1720. Гомуми тираж – 4360.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 748. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы